СУГЫШ ҺӘМ ТЫНЫЧЛЫК

Бабайлар кичергән фаҗигадән оныклар сабак ала белдеме?

> 4

КОММУНИЗМ УТРАВЫ:

Әлки районы Сихтермә-Хузангай авылының үзенчәлеге нидә?

> 5

ШАГЫЙРӘ СҮЗЕ

Сания Әхмәтҗанова – хатын-кыз һәм иҗат турында

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 63 (28836) | Җомга | 6 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

АЧЫ САБАК

БЕР ЕЛ ЭЧЕНДӘ МӘКТӘПЛӘРДӘ НИЛӘР ҮЗГӘРДЕ?

Бер ел элек 11 май көнне Казандагы 175 нче гимназиядә булган фаҗига бөтен илне тетрәндерде. Әлеге канлы вакыйгада 7 укучы һәм 2 укытучының гомере өзелде, күпме кешенең сәламәтлегенә зыян килде. Кайбер балалар әле һаман да өйләрендә укырга мәҗбүр. Бу фаҗига нинди сабак бирде?

> 6

Ишетми калмагыз

Бөек Җиңү көне алдыннан Татарстан делегациясе махсус хәрби операциядә катнашучы десантчыларга 40 тоннадан артыграк бүләк тапшырып кайтты. Беренче чиратта кирәкле әйберләрдән торучы бүләкләрне Премьер-министр урынбасары – Татарстанның Россиядәге вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин җитәкчелегендәге делегация алып барды.

Десантчылар өчен бүләкләрне өч район – Тәтеш, Арча, Саба районнары башлыклары, шулай ук «Ак Барс Холдинг» компаниясе (җитәкчесе – ВДВ ветераны Иван Егоров), «Агромастер» генераль директоры Илгиз Исламов, «Хәтнә» компаниясе генераль директоры Вәнил Әскәров, Домодедово шәһәре меценаты Феликс Җамалиев туплап җибәргән. Тәтеш районы хакимияте башлыгы Рәмис Сафиуллов март аенда үз акчасына Донецк һәм Луганск халык республикаларында яшәүчеләргә 40 тонна гуманитар ярдәм юллаган иде инде.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, ата-аналарның кызыксынуын исәпкә алып, мәктәпләрдә җәйге каникулның кайчан башланачагын аңлатты. Беренче, тугызынчы һәм унберенче сыйныфлар өчен соңгы уку көне итеп 24 майны билгеләү тәкъдим ителә. «24 майда Татарстанның барлык мәктәпләрендә тугызынчы һәм унберенче сыйныфларны тәмамлаучылар өчен соңгы кыңгырау яңгыраячак. Чыгарылыш кичәләрен 24 июньнән соң гына үткәрү тәкъдим ителә», – диелгән ведомство хәбәрендә.

Шулай итеп, беренче сыйныф укучылары 25 майдан ял итә, ә чыгарылыш сыйныф укучылары имтиханнар тапшыра башлаячак. Калган барлык сыйныфлар 31 майга кадәр укыячак. 1 июньнән аларның җәйге каникулы башлана.

Рамазан аенда, һәр елдагыча, «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны узды. Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды иганәчеләр хисабына авыру балаларга булышкан, авыр тормышлы гаиләләрне азык-төлек белән тәэмин иткән, социаль ифтарлар уздырган, мохтаҗларга фитр сәдакасы һәм фидия җыюны оештырган, качакларга ярдәм кулы сузган. Шулай итеп, хәйрия марафоны кысасында барлыгы 4780 кешегә ярдәм күрсәтелгән.

Марафонның изге эшләреннән берсе авыру балаларны дәвалау өчен акча җыюга бәйле. Акция Татарстанның төрле район-шәһәрләрендә яшәүче 20 балага тернәкләнү һәм дәвалау курсларын узу мөмкинлеге биргән. Моннан тыш «Зәкят» мохтаҗларга 1400000 сумнан артыграк фитр сәдакасы һәм фидия акчасын җыйган. 550дән артыграк мохтаҗ гаилә 3,5 тоннадан күбрәк азык-төлек белән тәэмин ителгән.

Һиһаять, җылыта. Татарстан Гидрометеорология үзәге фаразына караганда, шимбә – 7 майда көндез +13...+18 градус, төнлә 0...+4 градус булачак. Якшәмбе көнне термометрның терекөмеш баганасы күрсәткечләре +16...+21 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә +1...+6 градус күтәрелә. Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразы буенча, 9 майда явым-төшем ихтималы бик аз. Көндез +15...+20 градус, төнлә +2...+7 градус җылы булачак.

СОҢАРГАНЧЫ, КАДЕРЛИК!

Соңгы биш ел эчендә Татарстанда Бөек Ватан сугышы ветераннарының саны өч тапкыр кимегән. Бүген республикада әлеге дәһшәтле елларны күргән нибары 17938 кеше яши. Аларга бүген нинди ярдәм күрсәтелә?

Быел без Бөек Җиңү көнен 77 нче мәртәбә каршылаячакбыз. Бу бәйрәм – концерт белән салютка корылган бер көнлек вакыйга гына түгел. Җиңү көненә багышланган чаралар ел әйләнәсе дәвам итә, ветераннар – көндәлек кайгыртуда. Һәм бу шулай булырга тиеш тә. Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева шулай дип белдерде. «Быел Җиңү көне аеруча зур әһәмияткә ия. Бәйрәм лаеклы, тыныч үтсен өчен барлык чаралар да күреләчәк», – диде ул «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сан

✓ Бөек Ватан сугышы елларында Татарстаннан фронтка барлыгы **700** мең кеше киткән. Шуларның **378** меңе яу кырында ятып калган яисә хәбәрсез югалган.
✓ Сугыш елларында Советлар Союзы Герое исеменә **353** кеше лаек булган. Шуларның **185**е Татарстанда туган. Калган **168** геройның язмышы шулай ук безнең республикага бәйле. Моннан тыш республикада **51** кеше Дан орденының тулы кавалеры исемен йөртә.

Нинди ярдәм күрсәтелә?

«Республикада ветераннарыбызны кайгырту максатыннан төрле юнәлештәге программалар эшли, ташламалар каралган. Әйтик, ветераннарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә һәм юл йөрү буенча да 50 процент күләмендәге субсидия-ташлама каралган», – дип сөйләде Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова.

2022 елның беренче яртыеллыгында ветераннарга айлык түләү күләме сугыш инвалидларына – 8216, сугышта катнашучыларга – 6634, «Ленинград камалышында яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга – 4870, вафат булган инвалидларның (сугышта катнашучыларның) гаилә әгъзаларына – 3288, тыл хезмәтчәннәренә – 1663, хезмәт ветераннарына 4088 сумга арткан.

Ялгыз яшәүче сугыш ветераннарына, инвалидларга, тыл хезмәтчәннәренә исә аерым игътибар. «Бүген республикада яшәүче 2075 сугыш ветеранының өйләренә барып хезмәт күрсәтелә. Картлыгында ялгыз калган 56 кеше интернат-йортларда, психоневрология интернатларында тәрбияләнә», – дип аңлатты Эльмира Зарипова.

2008 елдан сугыш ветераннары, Россия Президенты указы буенча, торак белән тәэмин ителә. Дәүләт торак фонды соңгы 12 ел эчендә Бөек Ватан сугышы ветераннарына барлыгы 6114 фатир төзеп тапшырган. Шул исәптән унысын – узган ел, икесен – быел. Торак чиратында торган ветераннарның бүген һәммәсе дә торак белән тәэмин ителгән. Моннан тыш, барлыгы 19132 ветеранга торак шартларын яхшыртуга субсидияләр тапшырылган. 2022 елда Татарстанда алты Бөек Ватан сугышы ветеранының торак шартлары яхшыртылачак, тагын 10 йортка капиталь ремонт ясалачак.

Медицина ярдәменә килгәндә, быел барлыгы 12 меңнән артык ветеран диспансеризация тикшерүе, 285 кеше стационар дәвалау узган. «Иң еш мөрәҗәгатьләр травматология, ортопедия, офтальмология, гериатрия бүлекләренә», – диде Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков. Моннан тыш, 2022 елның беренче яртыеллыгында ветераннарны бушлай дару препаратлары белән тәэмин итү юнәлешендә барлыгы 255 мең сумлык 644 рецепт тапшырылган.

Бәйрәм көне

Җиңү көненә багышланган бәйрәм чаралары Татарстанның һәр районында узачак. Республика башкаласындагы төп бәйрәм чаралары гадәттәгечә Меңьеллык мәйданында булыр дип көтелә. Бауман урамында исә 77 ел элек булган Җиңү көнен кабатлаячаклар. 1945 елда Җиңү бәйрәменең төп өлеше нәкъ менә шушы урамда узган икән. Казанда һәм Татарстан буенча «Үлемсез полк» акциясе дә узачак. Соңгы мәртәбә ул 2019 елда булып, Россия буенча 10 миллион кешене берләштергән иде.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

	2017	2022
Сугыш инвалидлары	697	93
Сугышта катнашучылар	1348	266
Хәрәкәттәге армия составында булмаган хәрби частьларда хезмәт итүчеләр	508	88
Концлагерьларның элеккеге балигъ булмаган тоткыннары	204	116
«Ленинград камалышында яшәүче» билгесе белән бүләкләнүчеләр	195	109
Тыл хезмәтчәннәре	39574	12884
Сугышта катнашучыларның һәм сугыш инвалидларының тол хатыннары	3666	1823
Барлыгы	54844	17938

*Мәгълүмат 2022 елның 4 маена

ТИК СОҢГЫСЫ ГЫНА БУЛМАСЫН

Быел республикада юллар төзү һәм төзекләндерүгә 170 миллиард сум акча сарыф ителәчәк. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов хәбәр итте. Министр сүзләренә караганда, ел дәвамында республикада барлыгы 52,5 чакрым юл төзергә, 610,3 чакрым юлны төзекләндерергә җыеналар.

e-nkama.ru

Моннан тыш Татарстанда 597 метр озынлыктагы 12 күперне реконструкцияләү һәм гомуми озынлыгы 1 чакрымнан арткан тагын 15 күперне төзекләндерү планга кертелгән. Фәрит Хәнифов сүзләренә караганда, юл төзү, төзекләндерү өчен тотылачак акчаның 21,2 миллиард сумы республика программасы буенча бүлеп бирелгән. «Юллар төзекләндерүгә – 9,4 миллиард сумнан артык, аларны карап тотуга 6 миллиард сум акча сарыф ителәчәк. «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» илкүләм проектын тормышка ашыру максатында 6,7 миллиард сум акча каралган», – дип ачыклык кертте министр.

Республика юлларын төзү, төзекләндерү максатында сарыф ителәчәк акчаның 10,4 миллиард сумы федераль казнадан бүленгән. Әлеге акчага 12,8 чакрым озынлыктагы Горький шоссесын төзекләндерергә, «Салават Күпере» микрорайонына керү юлындагы Осиновская урамын тәртипкә китерергә, Вознесение трактының 3,8 чакрымлы беренче өлешен төзергә җыеналар. Хәтерләсәгез, Вознесение тракты узган елның август ахырында төзелә башлады. Аның беренче өлеше башкаланың Гвардейская урамы белән Җиңү проспектын тоташтырачак.

«2023 елда Вознесение тракты М7 трассасына чыгар дип планлаштырабыз. Шул рәвешле Казанга керү юллары, Мамадыш тракты белән Космонавтлар урамы да бераз бушаячак», – дип өметләндерә министр. Казан башкарма комитетының тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Сәләхетдинов әйтүенчә, бу эштә җир сатып алу мәсьәләсендә кыенлыклар бар. «Быелга планлаштырган эшнең ни дәрәҗәдә башкарылачагы әнә шуңа бәйле», – дип ачыклык кертте ул.

Быелга планлаштырылган тагын бер зур эш – М12 трассасы төзелешен дәвам итү. Моның өчен 100 миллиард сумнан артык акча бүленгән. Фәрит Хәнифов сүзләренә караганда, әлеге трассаның Татарстан аша узучы өлешләрен төзү эше график буенча бара. «Трассаның җиденче этабында юлның 90 проценты түшәлгән булса, сигезенче этабында Идел аша күпер салыначак. Аның озынлыгы 3,6 чакрымнан артачак. Бүген биредә металл конструкцияләр җыела», – дип ачыклык кертте ул.

Юллардагы куркынычсызлык мәсьәләсенә дә игътибар кимемәячәк, дип ышандыралар. Узган ел республика юлларында теркәлгән һәлакәтләргә анализ ясагач, Татарстан юлларында 167 куркыныч участок барлыгы ачыкланган. «Кызганыч, ел башыннан республика юлларында 85 кешенең гомере өзелде. Шуларның 22се – җәяүле. Шуңа күрә алдагы елларда юллардагы үлем-китем очракларын киметүгә зур игътибар биреләчәк», – диде Фәрит Хәнифов. Бу максатта 13 юл участогында тротуарлар төзү, 7 мең чакрым юлга юл тамгасы төшерү планлаштырыла. Моннан тыш республиканың 32 районында юлларны яктырту җыеналар. 30 районда юлларда ясалма тигезсезлек пәйда булачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Чират җитте почтага

Татарстан авылларында почта бүлекләре яңартылачак. Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең төбәк бүлеге политсоветы Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин бүген партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге башкарма комитетында шул уңайдан киңәшмә уздырды. Авылларда урнашкан почта элемтәсе бүлекләрен модернизацияләү партия проекты буенча гамәлгә ашырыла.

Фәрит Мөхәммәтшин, киңәшмәне ачып, ил җитәкчелегенең 2021 елда партия съездында авыл халкына почта хезмәтләре күрсәтү проблемасын хәл итү бурычын куйганлыгын искәртте. Дәүләт башлыгы Владимир Путин 2022–2025 елларда авылларда, шулай ук ерак җирлекләрдә урнашкан 25 меңнән артыграк почта бүлеген яңарту бурычын куйган иде. «Бердәм Россия» һәм «Россия почтасы» төбәк штабларын булдырган. Алар бөтен илдә почта бүлекләрен яңартуның барышын контрольдә тотачак. Быел программаны тормышка ашыруга 5 миллиард сум бирелгән.

«Сер түгел: соңгы елларда авылларның почта бүлекләре игътибардан читтә калып килде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Ә алар шәһәрдән, район үзәгеннән еракта яшәүчеләр өчен зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә Татарстанда партиянең әлеге проектында актив төстә катнашырга карар кылдык».

Быел Татарстанда 14 районда 15 почта бүлеген модернизацияләү көздә тотыла. Бу эш Теләче, Чүпрәле, Биектау, Актаныш, Ютазы, Лаеш, Алексеевск, Әлмәт, Яшел Үзән, Әтнә, Аксубай, Чистай һәм Яңа Чишмә районнарында башкарылачак.

Яңарту эшләре барышында почта бүлекләренең бинналары капиталь төзекләндереләчәк, шулай ук мебель һәм техник җиһазлар алыштырылачак. Бүлекләрдә, гадәти почта хезмәтләреннән тыш, даруханә пунктын ачып, дарулар сату яки интернет аша аларга заказ бирү мөмкинлеге пәйда булачак. Шулай ук күп кенә яңартылган бүлекләрдә дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәтеләчәк.

Фәрит Мөхәммәтшин, киңәшмәгә йомгак ясап, почта элемтәсе бүлекләрен модернизацияләү буенча партия проектын гамәлгә ашыруның авылда яшәүчеләрнең социаль проблемаларын хәл кылуга ярдәм итәчәген искәртте.

Халык кәефе

НИХӘЛЛӘРДӘ ЯТАСЫЗ?

Нурдания НИЗАМОВА (Буа районы Түбән Наратлы авылы):
– Кәефем бик шәп. Сөенеп, бәйрәмгә әзерләнеп йөрибез. Әле менә репетициядән кайттым. Җиңү бәйрәмендә узачак тантанада фронттагы кыз булып уйныйм. Өйдәге эшләрне дә онытмыйбыз. Иртә өлгерешле орлыклык бәрәңге алдык. Беренче партиясен 24 апрельдә үк утыртып куйдык. Кишер чәчтек, шалкан, редиска да утыртылды. Әлегә төп бакчага бәрәңгене утыртмый торабыз. Көннәр җылынуын көтәбез. Авылдашлар бакча эшенә тотынды инде. Берәүләр сукалый, икенчеләр тирес тарата. Кыскасы, авылда тормыш гөрли.

Нәкыйп СӘГЫЙРОВ (Мамадыш районы Түбән Яке авылы):
– Күңелнең сафланган чагы. Рамазан аен бик матур итеп озаттык. Шөкер, елдан-ел дин юлына басучылар арта. Авылыбызда тагын бер сөенеч – яңа мәчетебезне төзеп бетерделәр. Аны авылдашыбыз Рифат Мәхмүтов төзетте. Рифатның әтисе хөрмәтенә Мәсхүт мәчете дип исем бирдек. Яңа мәчеттә беренче җомга намазын 8 апрельдә укыдык. Авылдашларыбыз тәравихларга йөрде. Мәчет ике катлы. Аста – ирләр, өскә катта хатын-кызлар намаз укыды. Мәчетебездә дә ифтар уздырдык. Йөзгә якын кеше килде. Мәчет зур булгач, гает намазына да килүчеләр күп булды. 120ләп кеше намаз укыдык. Гыйбадәтханәне ачу тантанасы 27 май көнне булачак.

Лилия ӘСКӘРОВА (Минзәлә районы Тауасты Байлар авылы):
– Безнең әти ел саен 1 май көнне бәрәңге утырта. Кар явамы, боз явамы – берни дә туктата алмый аны бу шөгыленнән. Авылда иң беренче булып утыртабыз. Уңышы да яхшы була. Безнең якта җир өлгергән инде. Казырга авыр булмады, җир йомшак иде. Яшелчә бакчасына кишер чәчтек. Өйдәге помидор, кәбестә, борыч үсентеләрен бакчага чыгармадык әле. Аларга җылы кирәк, шуны көтәбез. Алдагы елларда ирем ягына – Балтач районына кайтачакбыз. Алла боерса, каенатама 70 яшь тула. Туган көне хөрмәтенә Коръән ашы уздырырга җыенабыз.

Тәнзилә ИДИАТУЛЛИНА (Кукмара районы Вахит авылы):
– Май бәйрәмендә өй юдык. Бер тотынгач, бөтен эшне эшләп бетерергә кирәк миңа. Башта залны гына юабыз дип уйлаган идек. Анннары инде бөтен җирне юасы килеп китте. Мунчаны да калдырмадык. Ирем дә булышты. Ул паласларны да юып бирде. Эт булсак булдык, чиста өйдә йокладык. Аллага шөкер, без эшләгәндә көне дә матур булды. Урын-җирләрне дә җиләтеп алдык. Инде хәзер әкренләп бакча эшенә тотынырга дип торабыз. Авылдашыбыз бөтен кешегә җитәрлек итеп яшелчә көлшәләре үстереп сата. Аннан кәбестәләр алып кайттык. Бәрәңге утыртырга иртә әле бездә. Җир салкын. Әле бит эшкә дә йөрисе бар. Фермада сыер савам. Эшләгән җиребездә дә өмә ясадык. Бар җирне җыештырдык. Бер генә теләк – исән-сау, авырмыйча яшәсәк иде.

Юрий ЕГОРОВ (Теләче районы Субаш авылы):
– Керәшен бәйрәмнәрен үткәрдек. Зиратны чистарттык. Өй яннарын да тәртипкә китердек. Әле бакча эшләренә иртәрәк дип уйлыйм. Көннәр дә салкынча тора. 10 ел буе әтине тәрбияләдем. Аның бакыйлыкка күчүенә 1 ел булды. Куптән түгел искә алу ашын уздырдык. Төп йортны кадерләп саклап тотабыз. Шунда туганнар белән кайтып йөрибез.

Зәлия МӨШӘРӘПОВА (Казан):
– Елларда туган авылыма кайттык. Һава торышы бик сөендермәде. Шуңа да әллә ни эшләп булмады. Өй юуны киләсе атнага калдырдык. Гает көнне ир-атларыбызның мәчеттән кайтуына коймак пешереп тордык. Бакча җыештырып, түтәлләр казыдык. Бәйрәм булгач, бәйрәмчә булсын дип, казан асып, шулпа пешердек. Әле эшлисе эшләребез бик күп. Шуңа да матур, кояшлы көннәрне көтәбез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА сорашты

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Тел байлыгы

Уиндоры шифаханәсендә ял итү төгәлләнеп килә. Кайбер истәлекләрне өйгә кайткач язармын дигән идем дә, әмма телнең гел кычытып торган көне. Рус мохитендә нинди хисләр кичерүем турында берничә сүз әйтмәсәм, күңел тынычланмас, ахрысы.

Шифаханә урманга терәлеп тора. Урман авызында ук утырып ял итәр өчен эскәмияләр куелган. Шунда кешеләрнең ни сөйләгәннәрен тыңлап утырырга яратам. Һәр нәрсә белән кызыксыну – миндә үзенә күрә бер авыру инде ул.

Менә яныма бер ир килеп утырды. Исәнләшкән булдык. Таныш булмаган кеше белән исәнләшү – монда үзе бер күркәм гадәт. Шулвакыт моның телефоны шалтырады. Дустымы, танышымы нидер сорады, ахрысы. Бу: «Я тебе дал бы, но пока самому нужен на...» – диде.

Дусты һава торышы белән кызыксынды, ахрысы, «Пока тепло, когда прохладно, я шапку, куртку надеваю на...» – дип җавап бирде яңа танышым. Евгений Петросянның бер шаян монологы искә төште дә елмаеп җибәрдем.

«Смехопанорама» карап барганнар әлеге монологны хәтерлиләрдер. Кыскасы, Россиягә японнар килә, бераз гына рус телен дә өйрәнмәкчеләр икән. Шуннан соң руслардан сорый болар: «Сездә «иди на...», «принеси на...», «попробуй на...», «выйди на...» дип сөйлиләр. Ул сүз нәрсәне аңлата соң?» – диләр. Руслар ни әйтергә дә белми, аптырап кала. Арадан берсе бөтен кыюлыгын җыя да: «Вы уж не обижайтесь на..., ул бездә бик күп мәгънәне аңлата торган сүз инде. Шуны һәр җөмлә саен кулланып, кыска һәм оста итеп, әйтәсен әйтәбез дә бирәбез», – ди.

Сүз, сөйләм теле, әлбәттә, катып калган бер догма түгел, ул үсештә, үзгәрештә булырга тиеш. Тик хикмәт шунда: кайсы якка үзгәрә бит!

Тел галимнәре әйтүенчә, рус телендә 195 мең сүз бар. Җир шарында рус телендә сөйләшүчеләр 300 млн тирәсе, диләр. Ни кызганыч, бөек Пушкин телен куллану даирәсе һаман тарая. Шуның өстенә ул шактый ук дәрәҗәдә фәкыйрьләнә дә бара. Рус телендә күп мәгънәне үз эченә алган сүзләр арта тора. Мин «на...»ны күз алдында тотмыйм. Мәсәлән, берәр әйбергә, йә берәр вакыйгага бәя биргәндә, «классно, клево, круто» кебек сүзләр һаман да күбрәк яңгырый, телнең тәме югала кебек. Пушкин үз иҗатында 21 мең тирәсе сүз кулланган дип ишеткәнем бар, әле шул 21 меңнең яртысына якынын бер генә мәртәбә кулланган, диләр.

Бүген рус теленә һәръяклап һөҗүм бара һәм аны саклап калу өчен төрле алымнар кулланыла. Мәсәлән, Бердәм дәүләт имтиханын фәкать рус телендә тапшырырга мәҗбүр итү. Башка телләрне кысу хисабына рус теленең абруен күтәреп булмаячак. Һәр халык үз телен үзе сакларга тиеш. Тел – һәр халыкның олы байлыгы ул, а җүнле кеше байлыкны юкка-барга әрәмшәрәм итми, аны, киресенчә, баета, арттыра. Әле «иң матур тел» дигән төшенчә дә бар – тикшеренүләр күрсәткәнчә, дөньяда итальян теле иң матуры санала икән, икенче урында – француз теле ди. Беренче унлыкта рус теле юк. Әмма иң матур тел – туган тел инде ул. Шуңа күрә чүпләмик без аны.

Янә теге яңа танышым искә төште әле. Мин аны биш минут чамасы тыңлап тордым. Шушы вакыт эчендә ул егермеләп сүз кулланды, аның яртысы чамасы сүгенү сүзләре иде. Кайчак мин дә сүгенеп куям үзе, татар күбрәк русча сүгенә инде ул. Әмма минем сөйләм, рус кардәшнеке белән чагыштырганда, сандугач сайравы кебек кенә.

ТЫНЫЧЛЫК ТУРЫНДА УЙЛАП...

Бөек Ватан сугышында Җиңүгә быел 77 ел тула. 1945 елның маенда бөтен совет халкы, Җиңү турында ишетеп, ачы күз яшьләре аша елмаеп сөенгәндә, дөньяга аваз салган сабыйга бүген инде – 77 яшь. Тулы бер кеше гомере үткән, сулар аккан, җилләр искән... Зур дәһшәт турында әтиләрдән ишетеп үскән минем буын да инде чәчләрен агартты, маңгайларына әзләр сызды, алтмыш яшьнең теге ягына таба чыгып барабыз...

Сугыш турында сүз чыкканда, безнең әтиләр – фронтовиклар – аз сүзле иде. Агач автоматтан атып, каһарманлыкка сусап үскән, романтикага омтылган борын асты кипмәгән малайларга нәрсә сөйләсен соң алар? Утлы дәһшәт кырында берцинди дә романтика юк дип әйтеп, борыннарны салындырсыннармы?

Сугыш романтикасы безнең күңелләргә исә Габдрахман Әпсәләмов романнары, киноэкраннарда барган исәпсез-хисапсыз кинофильмнар аша керде. Егет булып, дөньяга карашлар бераз үзгәргәч, Константин Симонов трилогияләре, Хисам Камалов романнары укылды. Боларында романтика түгел, реализм көчлерәк, сугышны фаҗига итеп ачу өстенлек алган иде. Соңгы әдипнең «Сайланма әсәрләр» җыентыгын, китап нәшрияты өчен кереш сүз язып, әзерләп бастырып чыгару да насыйп булды бу юллар авторына. Темаиы «Драматургиядә утлы еллар авазы» дигән кумәк җыентык әзерләп чыгарганда да өйрәнергә туры килгән икән. Шунда ул бер нәрсәгә игътибар итте: совет чоры авторлары теманы кай тарафтан гына торып яктыртмасыннар, нигездә прототипилы, прототвакыйгалы сюжет белән эш иткәннәр. Ягъни теманы бармактан суырмаганнар. Нәкъ менә шул сәбәпле, дулкынландыргыч әйберләр иҗат ителгән. Әйтик, менә Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» драмасын гына алып карыйк. Киносценарий итсәң, документаль нигезле ул әсәрдән менә дигән дулкынландыргыч фильм чыгар иде.

Экраннардан каралган күпсанлы кинофильмнар арасыннан өчесе хәтергә гомерлеккә уелып калган. Фашизмга карата нәфрәт, тормышка мәхәббәт һәм туган илгә бирелгәнлек белән сугарылган ул фильмнарда оныпылмаслык һәм онытырга ярамый торган кешелеклелек хисе салып калдырылган булган икән. Соңгысын, туган илгә бирелгәнлек дигәнен, ягъни патриотизм – ватанпәрвәрлек хисен соңгы вакытларда имгәтеп, кабыргасын сындырып бетерделәр, кайбер халыкларда ул милләтара дошманлыкка һәм үчкә – фашизмга әверелә язды. Иң аянычы: элекке совет киңлекләрендә канлы конфликтлар тәөенләнүгә китереп җиткерде. Тарих сабаклары онытылды.

Совет чорында, дистәләгән халыклар бер түбә астында яшәп ятканда, грузин режиссеры Резо Чхеидзе Севастопольдән хат ала. Хатта бер яшь егетнең, урлашуын таныл, милициягә килүен язалар. Ни өчен андый адымга баруын сорагач, ул: «Әле генә «Солдат этисе» дигән фильм карадым да бу якты дөньяда намус белән яшим дигән фикергә килдем», – дип җавап биргән. Бу юлларны язучының күңеленә тирән буразна сызып кереп калган кинофильм да – шул русча «Отец солдата» дип аталган картина инде. Җинаятьчелек юлына кереп китеп барган яшь егетнең тормышка карашын шулкадәр үзгәртә, кредо итеп намуслы яшәүне сайлауга этәрә алган ул фильмда тылсымлы нинди көч бар иде соң?

«Солдат этисе» – боевик түгел, анда сугыш эпизодлары минималь урынны алган. Сценарий авторы Сулико Жгенти 16 яшендә, үзе теләп, сугышка киткән. Күз алдына китерегез: борын астына мыек та тибеп өлгермәгән грузин үсмере. Сугышның аяусыз һәм авыр юлында диңгез десанты гаскәрләрендә хезмәт иткән яшь грузинга өлкән яшьтәге милләттәше – иген игеп, җиләк-җимеш үстереп яшәргә дип дөньяга килгән таулы ил крестьяны Георгий Махарашвили белән фронт сукмакларыннан бергә атларга туры килә. Яшь солдатларны пуля яңгыры астыннан саклап калырга тырышкан, гадәттән тыш физик көчкә ия булган шул карт, аларның хәленә кереп, үз җилкәсендә пулеметларын күтәреп барга торган булган. Новороссийск янында 1942 ел язында штыгы белән җир йомшартып бодай чәчкән ул картны бөтен дивизия белән яраткканнар, хөрмәт иткәннәр. Менә шул прототип, исемен дә үзгәртмичә, фильм каһарманына әверелгән дә инде.

Картинада ул, танкист улының яралануын ишетеп, госпитальгә чыгып киткән әти образында гәүдәләнерелгән. Әти кеше барып җиткәнче, улы, савыгып, яңадан фронт юлы буйлап китә. Карт, ничек итсә итеп, хәрәкәттәге армиягә кушыла, улы артыннан Берлинга таба атлый. Улы белән очраша ул. Ике катлы йортны штурмлаганда, яраланган бала әтисе кулында җан бирә. Җанны тетрәтә торган эпизод бит инде, әйеме? Грузин картының пуля һәм снаряд яңгыры астында янган иген кырын сүндерергә дип ташлануы да аңнан ким түгел. Яисә виноград куагын саклап, совет танкы алдына күкрәген киереп басуы да... Чын патриотизм менә шул инде ул: герман җирендәге йөзем тәлгәшен үлемнән саклап калып, яшь солдатларда нечкә күңеллелек, кешелеклелек хисләре уяту. Виноград куагын сабый баланы иркәләгән кебек иркәләп, җылы итеп сөйләшүче грузин картын сурәтләгән эпизодны караганда, күзләрегезгә яшь киләме сезнең? Табигатькә, кешелеккә, яшәүгә омтылышка капма-каршы булган сугышка нәфрәт хисләре уянамы? Елыйсыз һәм нәфрәтләнәсез икән, димәк, сез – үз илегезнең чын патриоты инде. Яисә Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» хикәясен укыганда, йөрәгегез елыймы?

«Сильнейший фильм – «Отец солдата». Настоящее кино, без коммунистического патриотизма, присущего того времени... Любимейшее кино. Я машинально прокручивал в голове и мурашки по коже бегать прекращали...» – дип язган рус телле блогерның хисләре бик тә аңлашыла миңа. Ракеталар очкан, туплар аткан якларда берничә сәгатькә генә тынлык урнаштырып, капма-каршы көчләрне шул фильмны карарга мәҗбүр итәргә иде... Яисә хәлиткеч карарлар кабул итәр алдыннан сәясәтче лидерлар һәм хәрби стратегларга кинотеатрга билет алып биреп, «Солдат этисе»н карарга җибәрергә иде. Сәнгать әсәренең тәэсир итү көче зур аның. Севастопольдәге карак егетнең күңелен үзгәртә алган икән, интеллектуаль яктан зирәгрәкләргә тәэсир итә алмас идемени?

Хәтергә кереп калган өч фильм дигән идем бит... «Иди и смотри» турында үткән Җиңү көне алдыннан язганмын икән. Өченчесе – «Судьба человека». Шолоховның шул исемдәге хикәясе нигезендә эшләнгән картина. Халыкара кинофестивальләрдә призлар белән бүләкләнгән бу фильм да – сугыш китергән ачы фаҗига турында. Юк, бу юлларны язганда, мин һич кенә дә сәнгать әсәрләре ярдәмендә дөньяны тамырдан үзгәртеп булыр дип уйламыйм. Әмма сугыш китергән драманы елга бер тапкыр бер-ике сәгатькә генә булса да күз алдыннан кичерсәк, тынычлык турында уйлаучылар саны артыр иде.

Хәзер бит яңа зур сугыш уты кабына калса, ставкалар күпкә югарырак. Күпләп юк итү коралы кулланылырга мөмкин. Атом бомбасы өлкәсендә танылган белгеч Роберт Оппенгеймер беренче атом бомбасы ясалуын күзәтеп торганнан соң, Америка конгрессы алдында шул процесс турында чыгыш ясый. Конгрессменнар аннан: «Атом бомбасының тәэсиреннән ничек итеп булса да сакланып буламы?» – дип сорыйлар. «Була», – дип, тирән ышаныч белән җавап бирә физик. «Нинди ысул белән?» – дигән сорау табигый рәвештә өстәлә. Доктор Оппенгеймер залны күздән кичереп чыга да бер генә сүз белән: «Тынычлык», – дип җавап бирә. Зур фаҗиганең төгәлләнүенә 77 ел тулган көннәрдә котылуның бердәнбер ысулы булган тынычлык турында төптәнрәк уйларга иде безгә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

КОММУНИЗМ УТРАВЫ,

ЯКИ ХУҖАЛЫГЫ НИНДИ – АВЫЛНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ШУНДЫЙ

Әлки районында «коммунизм утравы» буларак даны еракларга таралган Сихтермә-Хузангай дигән авыл бар. Кайчандыр сүнеп-сүрелеп барган авыл бүген чәчәк ата, зур планнар белән яши, бирәдә масштаблы төзелешләр бара. Халкы эшле дә, ашлы да. Районда кеше саны артып баручы бердәнбер авыл буларак та игътибарны үзенә җәлеп итте ул. Моның сере нидә дә, хуҗалыкның үзенчәлеге нәрсәдә? Без шул сорауларга җавап эзләдек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чуашлар бишеге

Сихтермә-Хузангай авылында бары тик чуашлар гына яши. «Сиктерме» чуаш телендә бишек дигәнне аңлата. Бүген авылда 351 кеше гомер итә. Ә бит кайчандыр авыллар бетү куркынычы әлеге саланы да урап узмый. Яшьләр китә, авыл картая. Әле ярый, бәхетләренә, Мари Иле Республикасындагы «Звениговский» җәмгыяте рәисе Иван Казанков авылдашларын ярдәменнән ташламый.

– Мари Иленнән Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлангач, миңа туган авылымнан кешеләр килде, – дип искә ала ул чакларны Иван Казанков үзе бер аңгәмәсендә. – Район башлыгы, башкарма комитет рәисе һәм авыл советы рәисе иде алар. Соңгысы минем туганым да әле. Гомумән, Сихтермәдә миңа һәркем кайсыдыр яклап туган булып чыга. Килделәр дә: «Авыл юкка чыга бит, ничек тә булса ярдәм ит әле, киңәш белән булса да», – диделәр. Ә нинди киңәш биреп була? Сүз белән теләсә нәрсә әйтергә мөмкин, ләкин акчасыз берни дә эшләп булмый. Безнең хуҗалык көчле иде. Уйладым да ярдәм итәргә алындым.

Шулай итеп, 2000 нче еллар башында «Хузангаево» җәмгыятенә нигез салына. Бүген әлеге хуҗалык – республиканың терлекчелек һәм үсемлекчелек белән уңышлы шөгыльләнеп килүче иң эре аграр компанияләренең берсе. Дүрт районда – чәчүлек җирләре, Әлки, Алексеевск һәм Чистай районнарында 11 меңгә якын мөгезле эре терлеге бар. Сөт, ит, җиде төрле ярма, көнбагыш эшкәртүдә дә алар Татарстанда алдынгылар рәтендә. Моннан тыш, токымлы атлар һәм сарыклар үрчетү белән шөгыльләнәләр. Киләчәктә маралларда алып кайтмакчылар.

– Иван Иванович Казанковка рәхмәттән башка сүз юк. Исән-сау гына була күрсен, – ди «Хузангаево» җәмгыяте җитәкчесе Евгений Чугунов. – Башка инвесторларга җирләр генә кирәк булса, ул беренче чиратта кеше, халык турында уйлый. Кайчандыр авыл үлеп бара, яшьләр китә, бер генә яңа йорт та төзелми иде. Ә бүген хуҗалык белән бергә авыл да чәчәк ата. 900 кеше эшле. Айга ике тапкыр хезмәт хакы алалар. Алга карап планнар төзиләр.

Авылның мәктәбе, чиркәве, яңа урамнары һәм зур планнары бар. Әле болардан тыш тирә-юньгә яхшы аты таралган офтальмология клиникасы да эшли.

Сыр заводы

Сезнең зур бүлмәдә рәт-рәт булып тезелгән киштәләрдә 132 тонна сыр саклананын күргәнегез бармы? Ә безгә күрергә насыйп булды. Хуҗалыкның 2018 елдан бирле эшләп килүче сыр заводы иде бу. Күңелгә килгән беренче уй: әллә каян читтән кертеләнне дә көтеп ятарга кирәкми, барысы да үзебездә җитештерелә бит!

Безне эш процессы белән таныштырып йөрүче технолог Алексей Красноперов сүзләре буенча, завод тәүлегенә 50 тонна сөт эшкәртүгә исәпләнгән. Әлеге вакытта 15 тонна сөт эшкәртеп, алты төрле 1,5 мең кг сыр ясыйлар.

– Яхшы, сыйфатлы сөтне үзебезнең фермалардан алып киләләр. Сыр ясау өчен антибиотиксыз, майлылыгы югары булган сөт кирәк. Аны бер көнне кабул итәбез дә икенче көнгә эшкәртә башлыйбыз. Сөтнең пастеризацияләнгән булуы мөһим. Шуннан соң сыр кайнату процессы башлана. Ул өч сәгать кайный. Аннан соң сыр түгәрәк һәм яссы формаларга салына. Алар прессланып, билгеле бер температурада һәм дымлылыкта саклана. Аннан соң сырлар ике тәүлек тозлана. Чираттагы этаплары – киптерү һәм төргәкләргә төрү, – дип аңлатты Алексей.

Ахырдан сырлар без күреп шаккаткан зур бүлмәдә өлгерүгә куела икән. Төрәнә карап, сырларның өлгерү вакыты төрлечә. Мәсәлән, «Россия» сырына өлгерү өчен – 60, «Тильзитер»га – 25, «Голландия» сырына 45 тәүлек кирәк.

– Безнең 800гә якын кибетебез бар. Өлгергән берен сатуга җибәрә торабыз, – ди белгеч. – Биредә февраль уртасыннан бирле өлгерә торган сырлар бар.

Алексей Красноперов әйтүенчә, илдәге соңгы вакыйгалар эшчәнлекләренә зур йогынты ясамаган.

– Бәяләрне элеккечә саклыйбыз. Җиһазларның, запас частьларның барысы да диярлек үзебезнеке. Оеткылар чит илдән кертелә иде. Аларны алыштырдык, – диде технолог.

Сырдан кала биредә атланмай да ясыйлар. Тиздән куертылган сөт заводы да ачарга ниятлиләр. Моның өчен барлык мөмкинлекләре дә бар. Боларга өстәп, авылда 1200 баш сыерга исәпләнгән ферма төзелеп ята.

Ярмалар

«Хузангаево» җәмгыятенең үсемлекчелек тармагы буенча да уңышлары зурдан.

– Без үзебез үстергән ашлык, техник һәм ярма культураларын үзебездә үк эшкәртергә тырышабыз, – ди Евгений Чугунов. – Бөртекледәрдән – он, катнаш мал азыгы, көнбагыштан май алабыз. Үзебезнең пекарнябызда берничә төрле ипи, камыр ризыклары әзерләнә. Эшкәрткәннән соң ярмалар шулай ук сатуга китә. Бөртекле ашлык арткан очракта «Звениговский» җәмгыятенә генә бирәбез.

Җиде төрле ярма эшләү цехын без дә карап чыктык. Хезмәткәрләр әйтүенчә, бер сменага 5 тонна ярманы капларга тутыралар. Хатын-кызларның күпчелеге шушы авылдан килеп йөри, күрше-тирә авыллар, районнардан эшкә йөрүчеләр дә күп.

«Звениговский» бренды астында чыга торган көнбагыш маеның исә чистартылганын да, чистартылмаганын да җитештерәләр. Уртача алганда, 0,9 литрлы шешәлесен – 1200, 5 литрлысын 500 данә тутыралар. Бер сменага ким дигәндә 4 тонна май ясыйлар.

– Бары тик үзебездә үстерелгән көнбагышны сыгып май җитештерәбез. Әле июнь ахырына кадәр җитәрлек чималыбыз бар. Яңа сезон башланганчы җиһазларны карап, төзәтеп алырга да вакыт кирәк бит, – диде биредә эшләүче хезмәткәр.

Эшләгәнгә – хөрмәт

Кыскасы, һәркемгә эш җитәрлек. Үзләренекенә дә, читтән килүчеләргә дә. Җәмгыятьтә барлыгы 900 кеше эшләсә, шуларның 480е – Хузангай җирлегеннән. Әле тагын кайсы хуҗалык өч ел эчендә үз эшчеләренә тулы бер урам йортлар салып бирә? Ә биредә нәкъ шулай эшләгәннәр. Ягъни хуҗалык кешеләрне эшле генә түгел, баш өстендә түбәле дә иткән. Авылда шундый 40 йорт салынган. Тагын егерме йорт Алексеевск районында сафка баскан. Бөтенләйгә төпләнеп калган очракта, эшче йортны үзенә рәсмиләштерә дә ала икән. Эшчеләрнең яшәр урыннарын гына түгел, тамак якларын да кайгырталар. Көненә өч тапкыр бушлай ашату өстенә, хезмәттә сынатмаган, тырышып эшләгән эшчеләргә ай саен колбаса һәм итләтә премия бирәләр. Евгений Чугунов әйтүенчә, эшчеләрнең уртача хезмәт хаклары – 30 мең сум.

Гомумән, бер авылда берничә мәйданда зур төзелеш безнең өчен гадәти булмаган күренеш булды. Быел Сихтермә-Хузангай авылында «Уяв» чуаш милли бәйрәме узачак. Бар көчләрен әнә шуңа куялар әлкиләләр. Әзерлек зурдан. Тематик экспозицияләр, дүрт сәхнә, кунак йортлары төзү, ике күл янын матурлау кебек эшләр белән мәш киләләр иде. Авыл уртасындагы күлгә аккошларга кадәр җибәрмәкчеләр. Икенче мәйданчыкта да төзелеш гөрли. Анысы алты метрлы манаралы кирмәнне нигез итеп алган этно-туристик комплекс булачак дип аңлаттылар. Аны сафка бастырыр өчен «Хузангай» кооперативы хәтта бетон блоклар эшләп чыгара башлаган. Әлеге яңа тарихи-туристик үзәк булачак масштаблы корылманы ел ахырына ачарга планлаштыралар.

Кыскасы, килгән кунакларга горурлык белән күрсәтерлек эшләре дә, уңышлары да бик күп хузангайлыларның.

АЧЫ САБАК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Адәм башында ниләр бар?

Бер сабак икенчегә ярыймы? Дүрт ай узгач, канлы вакыйга Пермьдә кабатланды. 18 яшьлек егет Пермь дәүләт илкүләм тикшеренүләр университетында ут ачты. Нәтиҗәдә 6 кеше һәлак булды, 30га якыны яраланды. Быелның апрелендә исә Ульяновск өлкәсендә «Рябинка» балалар бакчасында үзәк өзгеч вакыйга килеп чыкты. Сабый чагында шушы бакчага йөргән егет ике сабыйның, кече тәрбияченең гомерен өзде. Ул соңгы вакытта әбисе белән яшәгән. Беркайда да эшләмәгән, вакытын компьютерда үткәргән. Егет сәламәтлеге буенча психиатрда исәптә торган.

Күптән түгел Яшел Үзән районындагы бер авылда 82 яшьлек бабай күрше авыл мәктәбенә дулап килгән. Әйшә мәктәбендә 383 бала укый.

– Ул бабай – психик яктан авыру. Бездә аның оныгы укый. Өеннән ачу белән чыгып киткән, дигән хәбәр килеп ирешүгә, ишекләрне бикләп, хәвеф төймәсенә бастык. Полиция хезмәткәрләре вакытында килде, – ди Әйшә мәктәбе директоры Гөлнур Зиатдинова. – Психик яктан авыру булганнар табиблар күзәтүе астында дәвалансын иде. Бу бабайның гаиләсе табибларга бер атна элек мөрәҗәгать иткән, тик чарасы күрелмәгән. Күрелсә, безгә килмәс иде.

Гөлнур Зиатдинова әйтүенчә, соңгы бер ел эчендә мәктәптә иминлек мәсьәләсенә игътибар арткан. Видеокамералар урнаштырылган, металл эзләгечләр кайтартылган.

– Дөрес, әле авылларда һәр мәктәптә дә сакчылар куелмаган. Тиздән безгә дә махсус укытылган хезмәткәрләр куячаклар. Мәктәпне көндез – вахтерлар, төнлә каравылчы саклый. Ишекләр һәрвакыт ябык. Авыл дип тормыйлар, әти-әниләрнең күбесе балаларын үзләре китереп куярга, алып китәргә тырыша, – диде Гөлнур Зиатдинова.

Кулларда – «электрон беләзек»

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, республикада барлыгы 3593 уку йорты исәпләнә. Мәгариф оешмалары укучылар санына карап, дүрт төркемгә бүленә. Әйтик, беренчесенә – 1100, икенчесенә – 800дән артык, өченчесенә – 100–800, дүртенчесенә 100гә кадәр укучы белем алган белем йортлары керә. Узган ел уку йортларын терроризмнан саклау буенча 1380 уку йортында 259802,65 мең сумлык эш башкарылган. Монда видеокамералар кую, магнитлы ачкычкарталар булдыру һәм башкалар керә. 1–3 төркем мәгариф оешмалары хосусый сак хезмәткәрләре белән дә тәэмин ителгән. Алар өчен быел 1249,44 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Сакчыларга сәгатенә 220–250 сум акча түләнә.

Тукай районының мәгариф идарәсе бүлеге башлыгы Әлфәт Сабиров белдергәнчә, мәгариф оешмаларын саклау өчен республика бюджетыннан акча бүлеп бирелде.

«Авылда да мәктәп-бакчаларны ЧОПлар саклый. Дүртенче категориягә генә каралмаган ул, калганнарда бар. Бездә 27 бакча, 24 мәктәп исәпләнә. Шуларның 27сендә иминлекне хосусый сак хезмәткәрләре саклый», – диде ул.

Моңа кадәр әти-әниләр, мәктәпләрдә сак хезмәтенә акча җыялар, дип зарланса, быел андый шау-шу ишетелми. Мәктәпләрнең күбесен ЧОП хезмәткәрләре саклый. Иминлек мәсьәләсендә яңа технологияләр кулланган уку йортлары да бар. «Салават күпере»ндәге 188 нче гимназия керткән яңалыкларга әти-әниләр сөенеп бетә алмый.

– Кызыбыз Әминә – 2, улыбыз Камил 8 нче сыйныфта укый. Балаларга «электрон беләзек» бирделәр. Шуны киеп йөриләр. Әти-әниләрнең телефонына балаларыбызның ничәдә мәктәпкә баруы һәм кайтуы турында смс килеп тора. Болай күңел тыныч, – ди Казанның «Салават күпере» микрорайонында яшәүче Зәлия Мөшәрәпова.

Үзебез күрдек

Казан башкарма комитеты мәгариф оешмаларында иминлекне тәэмин итү буенча журналистлар өчен мәктәпләргә пресс-тур оештырды. Безне 149 нчы лицейда махсус киенгән, автомат тоткан хезмәткәрләр каршы алды.

– Элек мәктәп территориясе ачык иде. Барлык халык мәктәп сукмагыннан үтеп йөрде. Узган елгы ситуациягә кадәр без әкренләп халыкны тәрбияли башладык. Берничә капка бар иде, шуларны яптык. Иң куанычлысы шул: ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр табылды. Узган елда мәктәптә күп эшләр башкарылды. Бер ай эчендә коймаларны тәртипкә китердек, капкаларны алыштырдык, – диде директор Фирдәвес Вафина. – Ничек кенә булмасын, укырга килгән баланың гомере өчен мәктәп җавап бирә. Иминлек чаралары ул – техника кына түгел, кешенең мөнәсәбәте белән дә бәйле әйбер. Хезмәттәшләр, әти-әниләргә аңлату эшләре алып барабыз.

Директорның бүлмәсендә тавыш көчәйткечтән хәбәр бирү җайланмасы да урнаштырылган. Ул шуның аша бөтен мәктәпкә белдерү ясый ала. Шулай ук бүлмәсендә урнаштырылган монитордан урамдагы хәлне күзәтеп тора.

Казан мәгариф идарәсе башлыгы Ирек Ризванов бакча-мәктәпләрдә иминлек мәсьәләсендә күп нәрсәләр эшләнүен әйтте. Быел бу максатка 1,7 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

– Моңа кадәр сакчылар белән тәэмин итү проблемасы бар иде, хәзер ул мәсьәлә хәл ителде. Әти-әниләр моның өчен бер тиен дә акча түләми, – диде Ирек Ризванов.

Хәзер укучыларга мәктәпкә керү өчен электрон ачкычлар бирәләр. Аны югалткан очракта, теләсә кем табып, мәктәпкә үтә алмасмы соң? Моңа Ирек Ризванов: «Картаны югалткан очракта сакчылар бар. Алар барысын да күзәтеп тора, кизү торучы администратор да билгеләнгән. Алар балаларны таный», – дип җавап бирде.

Дөрес, мәктәпләрне көн дә автомат тоткан кешеләр сакламый. Алар мәктәпләрдә зур чаралар уздырганда чакырыла. Мәктәпләрне пенсионер әби-бабайлар саклаудан туктармы? Монысына мәгариф белгечләре: «Без ЧОП хезмәтләренә, ирләрне генә алыгыз, хатын-кызларны, пенсионерларны алмагыз, дип әйтә алмыйбыз. Алар махсус белгечләрне сайлый», – дип аңлаттылар.

Казан мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары Альберт Әхмәтовтан тәрбия турында да сораштык.

– Иминлек ул техник як кына түгел, оештыру ягын да карыйбыз. Республикада берничә программа эшли. Радикаль гаиләләрдәге балаларга игътибар ителә. Тестлар үткәрелә. Шуның нәтиҗәләре буенча үзләрен сәеррәк күрсәткән балалар белән өстәмә эш алып барыла. Барлык бала игътибарда. Мәктәпләрдә психологлар эшли. Шәһәрдә «Ышаныч» үзәге бар. Андагы хезмәткәрләр белән бергәләп эшлибез, – диде ул.

«Балалар да, без дә үзгәрдек»

Башкалабыздагы 175 нче гимназия фаҗигасенең шаһитлары булган, яшәү белән үлем арасында калучыларның да хәлләрен белештек. Һөҗүм итүчене ишектән кертмәс өчен юлына каршы төшкән завхоз ярдәмчесе Мулланур абый Мостафин катлаулы операцияләр кичереп, быелгы уку елында кабат үз мәктәбенә кайткан.

– Башыма пластинка куйдылар, үземне яхшы хис итәм. Мәскәүдә 58 көн дәваландым, шуның 30 көне реанимациядә үтте. Табиблар бик яхшы карады. Мәктәпкә кире кайтканда берниндИ курку да булмады. 7 ел гына эшләсәм дә, үземне гомер буе монда хезмәт куйган кебек хис итәм. Бу гыйбрәтле вакыйга безне саграк булырга өйрәтте. Капка төбендә кеше озаграк тукталып торса да, шикләнебрәк карыйсың. 11 май якынлашкан саен күңелдә ниндидер сискәнү бар, шик дип тә әйтеп булмый аны, – дип сөйли Мулланур Мостафин.

Мулланур абый әйтүенчә, мәктәпләрне ике метрлы койма корып кына саклап булмый, барлык мәктәпләрдә дә сак хезмәткәрләрен арттырырга кирәк. 175 нче гимназиядә эвакуацияләү буенча күнегүләр еш уздырылган, шуңа күрә укучылар фаҗига вакытында югалып калмаган. Директорның тавыш көчәйткечтән, ишекләрегезне ябыгыз, дип хәбәр бирүен дә мәктәпнең тырышлыгы дип бәяләде ул. Хәзерге вакытта гимназияне көн саен ике хезмәткәр саклый, пост буш тормый, ди. Капканы укучы, укытучылар да электрон ачкыч белән үзләре ачып керә.

– Начарлык эшләгән кешегә җәза бирергә кирәк. Җәза бирелмәсә, күңелсез хәлләр кабатланырга мөмкин. Кечкенә генә тәлгә дә битараф калырга ярамый. Тәрбияне арттырмыйча булмый. Начар дигән укучыда да яктылык чаткысы бар, шуны уята белергә кирәк. Безне укыганда шуңа өйрәттеләр. Әгәр бераз гына яхшылык эшли алсак та, куанабыз. Гомер буе шушы кагыйдә буенча яшибез, – ди Мулланур Мостафин.

«Фәридә – Алсу» дуэты солисты Алсу Сөнгатуллинаның улы да һөҗүм вакытында яраланган иде. Быел Ислам 9 нчы сыйныфны тәмамлый.

– Быелгы уку елы беребез өчен дә психологик яктан җиңел булмады. Балаларга гына түгел, әти-әниләр, укытучылар, әйләнә-тирәдәгеләргә дә авыр. Тормыш бөтенләй башка кебек тоела. Ислам да олыгаеп китте, бөтенләй икенче кешегә әйләнде. Туганнар, күршеләр дә шулай ди. Балалар саграк була башлады, кешеләргә ышанмау дигән нәрсә дә бар. Курку бетмәде, балалар катырак яңгыраган һәр тавыштан калтырап китә. Әле дә елыйбыз, күз яшьләрсез булмый, – ди Алсу.

Ни өчен шундый хәл килеп чыкты? Балаларның башында нинди уйлар бар? Без – өлкәннәр тәрбиядә нәрсәне күздән ычкындырдык? Бу нәфрәт каян килә? Әлеге сорауларга күпләр җавап эзләргә тырышты. Вакыт дәваласа да, яра гомергә кала. Мондый фаҗигаләр кабатланмасын, балалар бәхетле, озын гомерле булсын иде.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Илдар ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты:
– Ярты ел чамасы элек Дәүләт Думасында корал сату тәртипләрен үзгәртү мәсьәләсе каралды. Татарстан да, 18 яшьтә корал алу мөмкинлеге бирү бик иртә, дигән тәкъдим белән чыкты. Без ризалаштык, аны сатып алу яшен 21 яшькә кадәр күтәрдек. Коралга карата чикләүләр кертелде, яшь саны күтәрелде, белешмә алу тәртибе катгыйландырылды. Аны сатып алганда, теләсә кем, теләсә кайдан белешмә ала алмый. Тиздән беренче укылышта аучыларга корал алу мәсьәләсе каралачак. Әлеге тема дәүләт тарафыннан контрольдә тотыла.

Рафил НОГМАНОВ,
Татарстанның Иҗтимагый палата рәисе урынбасары:
– Әле вакыйгадан соң мәктәпләр үзләрен саклау турында уйлый башлады. Укучыларга карата игътибар артты. Баланың холкы нинди, нәрсә белән шөгыльләнә дип кызыксыналар. Президент мәктәп-бакчаларны әби-бабайлар түгел, көчлерәк хезмәткәрләр сакласын өчен сак хезмәтенә акча бүлеп бирде. Нәрсәдер эшләнде, әмма күбесен эшлисе бар әле. Мәктәпләрдә белем бирү, имтиханга әзерләнү генә түгел, тормышка, тәрбиягә өйрәтү эшен дә алып барырга кирәк. Шул ук мәктәпләрдә укучыларга геройларны күрсәтсеннәр. Әйтик, Әфган, Чечня сугышында катнашучыларны, хезмәт батырларын, заводлардагы тәҗрибәле токарьны ник чакырмаска? Элек без мәктәптә җыештыручының кем икәнен дә белми идек. Үзебез юа, эшли идек. Хәзер балаларны эшләтергә ярамый. Хезмәт тәрбиясен кертү турында уйларга, үзгәртергә кирәк.

ЫШАНМА СҮЗЕНӘ, КАРАМА КҮЗЕНӘ

Мошенниклар көндәлек тормышыбыздагы бер генә яңалык-үзгәрешне дә игътибардан читтә калдырмый. Бу көннәрдә алар халыкны төп башына утыртуның тагын берничә яңа ысулын уйлап тапкан. Аерым алганда, мошенниклар дару өчен компенсация кайтара, ябылган чит ил кибетләренең складларын бушата башлаган. Җиңү көне алдыннан ветераннарны аулаучылар да бар.

«ВТ» архивыннан

МОШЕННИКЛАР КОРБАНЫ БУЛМАС ӨЧЕН

➤Банк хезмәткәрләре беркайчан да клиентларының шәхси мәгълүматларын сорап, йә булмаса, акчаңны югалта аласың, дип куркытып шалтыратмый. Клиентның исәп-хисап счеты белән бәйле шикле операцияләр булган очракта да банк аларны автомат рәвештә туктатачак.

➤Банк хезмәткәре клиентның банк картасы номерларын, смс аша килгән парольләрне дә сорамый. Гомумән, үзегез турындагы шәхси мәгълүматны, банк картасы номерларын, смс аша килгән кодларны беркемгә дә хәбәр итмәгез. Банк хезмәткәре башта кредит рәсмиләштереп, аннары шуны ниндидер билгесез счетларга күчерүне сорый икән – шулай ук шикләнергә җирлек бар.

➤Мошенник корбаны булмас өчен иң элек 112 номерына яки «ышаныч телефоны»на шалтыратып, теге яки бу номер буенча сезгә кемнең шалтыратуын, ул сөйләгән сүзләрнең дөресме-юкмы икәнлеген белешергә кирәк.

➤Интернет аша товар сатып алганда яки ниндидер хезмәт өчен акча күчерер алдыннан иң элек бу сайтны яхшылап тикшерегез, анда язылган кайтавазларны өйрәнегез. Сайт аша әйбер сатып алганда акчаның бер өлешен алдан түләп куярга кушсалар да, ризалашмагыз.

➤Телефоннан шалтыратып: «Туганыгыз бәлагә тарыды», – дисәләр, трубканы куеп, иң элек шул кешенең үзенә шалтыратып, бу сүзләрнең дөресме-юкмы икәнлеген белешегез.

➤Әгәр телефон яки сайт аша шикле кешегә акча күчерергә өлгергән булсагыз, банк картагызны блокка куеп, бу хакта банкка хәбәр итегез. Полициягә дә гариза язарга кирәк. Күчергән акчам әллә ни зур түгел иде дип, кул селтәргә ашыкмагыз. Мошенник бүген ун сумсыз калдырса, киләчәктә 100 мең сумыгыздан ук колак кактырырга мөмкин.

Өчнең берсе дә юк

Килеп туган вазгыять аркасында мошенниклар бераз тынып торган кебек тоелган иде. Бу көннәрдә алдау-йолдау очраклары турындагы хәбәрләр кабат ишетелә башлады. Хәзер мошенниклар үзләрен сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Росздравнадзор) вәкиле дип таныштырып шалтырата икән. Алар ниндидер ялган ташламалар вәгъдә итә, сыйфатсыз күрсәтелгән медицина ярдәме өчен компенсация алырга, дару, биологик актив кушылмалар (БАД) сатып алганда түләгән акчаның бер өлешен кире кайтарырга ярдәм итүләрен әйтә. Әмма бу ярдәм өчен иң элек фәлән картага акча күчерергә кушалар. «Безнең идарә бары тик контроль һәм күзәтчелек эше белән генә шөгыльләнә. Безнең хезмәткәрләр кешедән берничек тә акча сорый алмый», – диелгән ведомствоның рәсми сайтында бу уңайдан. Белгечләр мошенниклардан мондый эчтәлектәге шалтырату алган кешеләрдән (499) 578-01-06 номеры буенча шалтыратып хәбәр итүләрен сорый.

Россиядә дарулар белән бәйле алдау очраклары соңгы бер-ике айда аеруча популяр. Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә мошенниклар Сәламәтлек саклау министрлыгы хезмәткәрләре исеменнән шалтырата башлаган дип хәбәр иткән идек. Ул чакта кырыгалдарлар кешеләрне илдә даруларга кытлык булуына ышандырып, запаска дару алырга үгетләде. Ышанмас җиреңнән ышанырсың. Ник дигәндә, нәкъ менә шул көннәрдә халык шикәр комы белән беррәттән, күпләп дару да җыярга керешкән иде бит.

Мошенниклар соңгы арада Россиягә кертелгән чикләүләр аркасында бездә күп кенә чит ил кибетләренең ябылуыннан да отып калырга уйлаган. IKEA, H&M, Zara кебек халык арасында аеруча популяр булган ябылган кибетләрнең складта сакланган товарларын зур ташлама белән эләктереп калырга «ярдәм итә» башлаган алар. Бу хакта иң беренчеләрдән булып «Инстаграм»дагы танылган блогерларның берсе хәбәр итте. IKEA кибетендәге өстәлне 50 процент ташлама белән сату турындагы игъланга ышанып, алдана язган ул.

– Үзен шушы кибетнең элеккеге хезмәткәре дип таныштырган Владимир исемле ир-атның белдерүдәге рәсеме урынында кибетнең логотибы тора иде. Шалтыратып сөйләштем. «Элеккеге хезмәткәрләрнең кибетнең складына керергә мөмкинлеге бар. Безгә дә акча эшләргә кирәк бит. Шуңа күрә кирәк кешегә складтагы товарларны ташлама белән сатарга булдым», – ди бу. Моңа бик сөендем. Бу кибетне бик яратам. Элегрәк андагы товарларны гел үземнең сәхифәмдә күрсәтеп бара идем. Әмма Владимир минем сорауларны игътибарсыз калдырып, ун минут саен нинди товар сайлавымны сорап, аны кулга төшерү өчен тиз арада акча күчерергә кирәклеген әйтте, ашыктыра башлады. Шуннан моның алдакчы икәнен аңлап алдым, – дип сөйләде блогер. Ул уздырган туры эфир барышында мондый төр мошенниклык корбаннарының шактый булуы ачыкланды.

Казанда яшәүче Эльвира үзен Zara кием кибетенең элеккеге хезмәткәре дип ышандырган кешегә 5 мең сум акчасын да күчерергә өлгергән. «Кибетнең рәсми сайтыннан өч төрле кием сайлап, моңа шуларның фотоларын җибәрдем. «Болар складта бар. Барысы бергә 4999 сум булачак», – дип язды бу. Шатландым, билгеле. Мин сайлаган өс киемнәренең берсе-берсе ким дигәндә 3 мең сум тора бит. Ә монда ул 5 меңгә генә төшәчәк. Теге кеше түләү өчен ссылка җибәргәч, шуның буенча кереп, акча күчердем. Шуннан бу кеше шалтырату, смсларга бөтенләй җавап бирми башлады. Полициягә гариза яздым инде. Никтер очына чыга алмаслар кебек», – ди Эльвира.

Ашыктырса, шикләнү

Татарстан Кулланучылар берлеге советы рәисе Марс Исмәгыйлев мондый алдау очракларының пәйда булуында кешеләр, нигездә, үзләре гаепле дигән фикердә. «Бүгенгедәй катлаулы чорда бу – гадәти күренеш. Берәүләр акчаны янга калдырырга, йә булмаса, дефицит товарны кулга төшереп калырга тырышканда, икенче берләре моннан файдаланып, акча эшләп калырга тырыша. Шуңа күрә гади генә кагыйдәне истә калдырыгыз: әгәр сезгә теге яки бу әйберне бик яхшы ташлама белән алып калырга тәкъдим итәләр икән, шикләнергә җирлек бар. Мондый шикле тәкъдимнәргә ышанмагыз, аң булыгыз», – ди ул.

Психология фәннәре кандидаты Лилия Һадиева мошенникларның бик оста психолог икәнлекләрен дә истән чыгармаска киңәш итә. «Кырыгалдар кешедә ни рәвешле, нинди сүзләр белән ышаныч уятырга кирәклеген бик яхшы белә. Шуңа күрә еш кына аның алдакчы икәнен җиңел генә ачыклап та булмый. Шулай да аны «сата» торган берничә сыйфат бар. Әйтик, кырыгалдар еш кына кыска-кыска җөмләләр белән, бик тиз сөйли. Моны ул кешенең аны-моны уйларга, анализларга вакыты булмасын өчен махсус эшли. Аның күп кенә сүзләре боерык сыман яңгырый. Әгәр кеше озак уйлап торса, ул әйткәннәрне эшләүдән баш тартса, мошенник, ачудан тавыш күтәрергә, дорфа сөйләшергә дә мөмкин. Шуңа күрә шушы билгеләрнең берсен генә сизсәгез дә, сөйләшүне шундук туктатырга кирәк», – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Елның елында 9 Май – Җиңү көне алдыннан да мошенниклар активлаша. Быел да искәрмә булмаска охшап тора. Ник дигәндә, беренче корбаннар күренә башлады инде. Берничә көн элек Чаллыда яшәүче 89 яшьлек әби 3 мең сум акчасыннан колак каккан. Подъезд төбендә әби таныш булмаган бер ханымны очраткан. Үзен Пенсия фонды хезмәткәре дип таныштырган кырыгалдар Җиңү көне алдыннан әбигә 12 мең сум акча тапшырырга килгәнен әйткән. «Корбан»ының өенә кергәч, кулында 15 мең сум гына акча булуын әйтеп, аннан 3 мең сум «сдача» алган ул. Әби исә үзенә 12 мең сумлык уенчык кәгазь акча калдырып киткәннәрен соңрак кына аңышкан. Хәзер бу факт буенча җинаять эше кузгатылган.

Хокук сакчылары Җиңү көне якынлашкан көннәрдә өлкәннәрне аеруча сак булырга чакыра. Таныш булмаган кеше белән аралашмаска, аларны өйгә кертмәскә кирәк. «Бәйрәм алдыннан Бөек Ватан сугышы ветераннарына бирелә торган 10 мең сум акчаны да Пенсия фонды шәхси исәп-хисап счетына яки саклык кенәгәсенә күчерә», – диелә хәбәрдә.

Эзе – монда, үзе – тегендә

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсендәге бүлек башлыгы Ленар Гәрәев сүзләренә караганда, кырыгалдарлар үзләре кулланган төп алдау ысулларын үзгәртергә ашыкмый. Халыкны төп башына утыртуның иң популяр ысулы булып телефон аша кылынган җинаятьләр кала бирә. Рәсми саннардан күренгәнчә, Россиядә ел саен 400 меңләп кеше телефон аша эш итүче кырыгалдар корбаны була. Татарстанда исә көненә уртача 30 кеше телефон аша алдана.

«Бу төркемгә кергән җинаятьләрнең 33 процентын банкның куркынычсызлык хезмәтеннән дигән булып, алдап шалтыратулар тәшкил итә», – ди бүлек башлыгы. Рәсми саннардан күренгәнчә, соңгы биш елда республикада киберҗинаятьләр саны ун тапкыр арткан. Чагыштыру өчен: 2017 елда Татарстанда шундый 4 мең очрак теркәлгән булса, узган ел бу сан 14 меңгә җиткән.

Соңгы арада республикада интернет аша әйбер сатып алганда, бушлай белдерү сайтлары аша алданучылар саны да артып киткән (17,5 процент). Шуңа күрә хокук сакчылары кирәк әйберне интернет аша – онлайн рәвештә генә сатып алырга күнеккән кешеләргә товарны маркетплейс, ышанычлы оешмалардан гына заказ бирергә киңәш итә. «Арзан бәягә кызыгып, шикле оешмадан онлайн рәвештә әйбер сатып алырга кирәкми. Заказ биргәч, буш посылка килде яки бөтенләй килмәде дип зарланып мөрәҗәгать итүчеләр күп», – ди Ленар Гәрәев.

«Туганың бәлагә тарыды», – дип шалтыратулар да мошенниклар арасында популярлыгын югалтмый икән. Кырыгалдарлар тарафыннан кулланылган иң төп алдау ысулларының беренче өчлеген нәкъ менә шушы төр җинаятьләр йомгаклый. Ленар Гәрәев сүзләренә караганда, мошенникларның күбесе – чит төбәктә яшәүчеләр. Агымдагы елның өч аенда гына да чит төбәкләргә оештырылган командировка барышында 395 кырыгалдарны тоткарлаганнар. Чагыштыру өчен: узган ел чит төбәкләргә оештырылган шундый 600 командировка барышында 200ләп мошенникның эзенә төшкән булганнар.

Быелдан башлап хокук сакчылары мошенниклар белән бер сүздә булган арадашчыларны да җаваплылыкка тарта башлаган. Элегрәк курьер булып еш кына таксистлар йөргән булса, соңгы арада алар бу эштән баш тарта икән. Шуңа күрә бүген җинаятьчеләр үзләренә ярдәмчене, нигездә, «Телеграм» каналы аша эзли башлаган. Мошенникларга ярдәм итүче арадашчылар арасында хәзер яшьләр, хәтта балигъ булмаганнар да очрый. Шуңа күрә нәрсәнедер илтеп биргән, алып кайткан өчен бик зур акча вәгъдә итсәләр, шикләнергә кирәк, ди белгечләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

9 май | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 М.Мәһдиев. «БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ». Телевизион фильм 12+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
07.10 «Сугыш чоры җырлары» 6+
08.00, 14.30, 19.01, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «В ДВУХ ШАГАХ ОТ «РАЯ» 0+
09.45 Торжественное шествие войск Казанского гарнизона, посвящённое 77-ой годовщине Великой Победы 0+
11.00 «Батырларга хат» 6+
12.00 «Габдрахман». Док. фильм премьерасы 12+
13.00 «Йөрәкләрдә һаман ут яна…» Концерт 6+
14.45 «Бессмертный полк – 2022» 0+
16.00 «Йөрәкләрдә һаман ут яна…» Концерт 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Батырларга хат» 6+
18.00 «Соотечественники». Дамир Исламов 12+
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания» 0+
19.30, 21.00 Праздничный концерт 0+
22.00 Праздничный салют 0+
22.05 «Бессмертный полк – 2022» 0+
23.00 «ТЕНЬ ВРАГА» 16+
00.30 «Соотечественники». Муса Гареев 12+
00.55 «Соотечественники». Дамир Исламов 12+
01.20 «Песни Победы» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 Р.Харис. «КҮЗЛӘРЕҢНӘН ҮБЕП». С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле 12+
07.30 Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәев турында телеочерк 6+
08.30 «Йөрәкләрдә һаман ут яна». Концерт 6+
09.45 Казан гарнизонының Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган тантаналы узышы 6+
11.00, 18.00, 20.30, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 00.15 «Ватандашлар». Җавап итеп аваз салырмын. Ф.Яруллин 6+
12.05 «Батырларга хат. Письма героям» 6+
14.45 «Үлемсез полк-2022» 6+
16.00 «Йөрәкләрдә һаман ут яна». Концерт 6+
17.00 «Габдрахман». Док. фильм премьерасы 12+
18.55 Фашизмга каршы сугышта һәлак булганнарның якты истәлегенә… Бер минутлык тынлык 6+
19.01 «Ватандашлар». Гази Заһитов. Исемсез батырлык 6+
19.30, 21.00 Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган бәйрәм концерты 6+
21.30 Б.Сәлахов. «ЯРАТЫЛМЫЙ КАЛГАН ЯРЛАР». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле 12+
23.15 М.Мәһдиев. «БЕЗ – 41 ЕЛ БАЛАЛАРЫ» 6+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.50 Новости
05.10, 11.00, 23.50 «День Победы». Праздничный канал
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы (S)
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.00, 22.10 Большая премьера. «ДИВЕРСАНТ. ИДЕАЛЬНЫЙ ШТУРМ» (S) 16+
21.00 «Время»
01.50 Фильм «НА ВОЙНЕ КАК НА ВОЙНЕ» 12+

РОССИЯ 1

04.00 Мария Шукшина, Гела Месхи, Валентина Попова, Фёдор Гуринец, Шорена Шония. «НИ ШАГУ НАЗАД!» 12+
08.00 «День Победы». Праздничный канал
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвящённый Дню Победы
11.00 «День Победы»
12.00, 14.00, 20.00 Вести
12.30 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню Победы
14.30 Бессмертный полк. Прямой эфир
16.20, 19.00 Премьера. «ЧЕРЕЗ ПРИЦЕЛ» 12+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Премьера. Павел Прилучный, Павел Чинарёв, Евгений Серзин, Алексей Филимонов, Дмитрий Лысенков, Тимофей Трибунцев, Александр Лыков. «ДЕВЯТАЕВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 14.45, 17.55, 20.55 Новости
06.05, 14.50, 18.00, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «СМЕШАРИКИ». Мультфильм 0+
09.30 «Страна героев» 12+
10.10, 00.45 «Бессмертный футбол». Специальный репортаж 12+
10.25 «С мячом в Британию». Док. фильм 6+
12.00, 12.35 «Личный номер» 12+
13.55, 01.05 Футбол. Тинькофф. Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
15.30, 18.30, 19.05 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Мужчины. «Финал 6-ти». . 1/2 финала. Прямая трансляция из Казани
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма». Минута молчания
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Рома». Прямая трансляция
00.15 Тотальный футбол 12+

НТВ

04.10 «Великая Отечественная» 0+
05.40, 08.15 Максим Радугин. «ПОСЛЕДНИЙ ДЕНЬ ВОЙНЫ» (S) 16+
08.00, 11.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы.
11.30 Аристарх Ливанов. «ДЕД МОРОЗОВ» (S) 16+
15.00, 16.30 «ТОПОР» (S) 16+
17.00 Военный фильм «ТОПОР. 1943» (S) 16+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.35 «В АВГУСТЕ 44-ГО…» 16+
21.25 Премьера. Андрей Смоляков. «ТОПОР. 1944» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Свидание с войной» 16+
09.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ В ЭДЕМ» 16+
14.20 «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ» 16+
15.55 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
18.50 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.00 «ПОДКИДЫШ» 16+
21.55 «БРИДЖИТ ДЖОНС-3» 16+
23.50 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ» 16+

ЗВЕЗДА

05.00, 06.00, 07.00, 08.00, 09.00 Новости дня 16+
05.10, 06.10, 07.10, 08.10 «ЖИВЫЕ И МЕРТВЫЕ» 12+
08.45 «История военных парадов на Красной площади. 1945 год» 16+
10.00 Москва. Красная площадь. Военный парад, посвященный 77-й годовщине Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.
12.00, 13.00, 14.00, 15.00, 16.00, 17.00, 18.00, 19.00 Новости дня 16+
12.15 «Специальный репортаж». Премьера! 16+
13.30, 14.10, 15.10 «Вечная Отечественная». Док. сериал 12+
16.15 «Они сражались Za Родину». Док. фильм 16+
17.05 «Великая Отечественная в хронике ТАСС». Док. фильм 12+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания.
19.30 Концерт, посвященный 77-й годовщине Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.
22.10 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» 16+

10 май | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 З.Зәйнуллин. «41НЕҢ АРБАЛЫ ХАТЫННАРЫ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
20.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
23.00 «УСЛОВИЯ КОНТРАКТА» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Магуба Сыртланова. Вырваться из лучей вражеских прожекторов 12+
00.50 «Вехи истории». Телефильмы. «Они поднимали страну» и «Большая нефть Татарии» 12+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ-2» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Туган җир» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» 12+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 «Россия от края до края» 12+
06.30 Фильм «ВРЕМЯ СОБИРАТЬ КАМНИ» (S) 12+
08.10 Фильм «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ» 12+
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Вольф Мессинг. «Я ВИЖУ МЫСЛИ ЛЮДЕЙ» 16+
11.10, 12.15 «Видели видео?» 0+
13.35 «Наркотики Третьего рейха» 16+
14.30 Фильм «ВОДИТЕЛЬ ДЛЯ ВЕРЫ» (S) 16+
15.15 «Водитель для Веры» (S) 16+
16.55 Владислав Галкин, Александр Балуев, Ольга Остроумова, Валентин Гафт в многосерийном фильме «ПО ТУ СТОРОНУ ВОЛКОВ» (S) 16+
18.20 «По ту сторону волков» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Леонид Бичевин, Мария Андреева, Александр Бухаров. «МОЛЧАНИЕ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 «АнтиФейк» 16+

РОССИЯ 1

06.25, 09.30 Павел Баршак, Василиса Семашкова, Екатерина Смирнова, Полина Пушкарук, Мария Баева, Александра Милешина, Сергей Пускепалис, Константин Милованов. «ЧЕРЕЗ ПРИЦЕЛ» 12+
09.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
12.05 Павел Прилучный, Павел Чинарёв, Евгений Серзин, Алексей Филимонов, Дмитрий Лысенков, Тимофей Трибунцев, Александр Лыков. «ДЕВЯТАЕВ» 12+
15.15, 18.15 Мария Голубкина, Александр Бухаров, Любовь Толкалина, Алексей Гришин. «НИ К СЕЛУ, НИ К ГОРОДУ…» 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Премьера. Мария Голубкина, Александр Бухаров, Любовь Толкалина, Алексей Гришин. «НИ К СЕЛУ, НИ К ГОРОДУ…-2» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 15.55, 20.55 Новости
06.05, 13.05, 21.00, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «ПУТЬ ДРАКОНА» 16+
11.10, 12.35 «НОЛЬ-СЕДЬМОЙ» МЕНЯЕТ КУРС» 16+
13.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/2 финала. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – ЦСКА. Прямая трансляция.
16.00 Футбол. БЕТСИТИ Кубок России. 1/2 финала. «Динамо» (Москва) – «Алания Владикавказ». Прямая трансляция
18.30 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Мужчины. «Финал 6-ти». Финал. Прямая трансляция из Казани.
21.40 Бокс. Bare Knuckle FC. Майк Вертрила (Россия) против Сиримонгхона Ламтуана (Таиланд) 16+
00.00 «ХРАМ ШАОЛИНЯ» 16+
01.55 Смешанные единоборства. AMC Fight Nights. Геннадий Ковалёв против Марсио Сантоса. Трансляция из Владивостока 16+
03.35 «Наши иностранцы» 12+

НТВ

05.15 «Великая Отечественная» 0+
06.00, 08.15 Фильм «ОДИН В ПОЛЕ ВОИН» (S) 12+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
09.30, 10.20 «ТОПОР» (S) 16+
11.35 Военный фильм «ТОПОР. 1943» (S) 16+
13.30 Военный фильм «ТОПОР. 1944» (S) 16+
15.00 Михаил Евланов, Татьяна Казючиц, Аристарх Ливанов. «МАМКИНА ЗВЕЗДОЧКА» (S) 16+
16.15 Премьера. Фильм «МАМКИНА ЗВЕЗДОЧКА» (S) 16+
19.35 Премьера. Антон Хабаров, Екатерина Олькина. «АЛЕКС ЛЮТЫЙ. ДЕЛО ШУЛЬЦА» (S) 16+
23.10 Евгений Цыганов, Николай Фоменко, Мария Крылова, Семен Трескунов. «У АНГЕЛА АНГИНА» (S) 16+
00.40 Константин Хабенский. «СОБИБОР» (S) 12+
03.20 Юрий Колокольников, Полина Максимова. «ОБРАТНЫЙ ОТСЧЕТ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ЗОЛУШКА» 16+
10.45 «ЗОЛУШКА С РАЙСКОГО ОСТРОВА» 16+
12.35 «ДНЕВНИК БРИДЖИТ ДЖОНС» 16+
14.30 «БРИДЖИТ ДЖОНС: ГРАНИ РАЗУМНОГО» 16+
16.40 «БРИДЖИТ ДЖОНС-3» 16+
19.00 «КОРЗИНА ДЛЯ СЧАСТЬЯ» 16+
22.40 «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ» 16+
00.30 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ» 16+
03.45 «ПРОВОДНИЦА» 16+
06.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
05.45 «УЛИЦА ПОЛНА НЕОЖИДАННОСТЕЙ» 12+
06.55, 08.15 «КАРНАВАЛ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
10.00, 13.15, 18.15 «ЦЫГАНКИ» 16+
21.15 «ТРИ ДНЯ В ОДЕССЕ» 16+
23.20 «ЖИВЫЕ И МЕРТВЫЕ» 12+
02.40 «Зафронтовые разведчики». Док. сериал 16+
03.15 «Москва фронту». Док. сериал 16+
03.35 «ВЕРДИКТ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 9–15 МАЙ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Аптырап калганда, бер туганыгыз төпле киңәшләрен биреп сөендерер. Өй мәшәкатьләре күп вакытыгызны алса да, зур канәгатьлек хисе китерер. Акча мәсьәләсе, ниһаять, итәктән тартудан туктар.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Бердәнберегезгә игътибарлырак булырга кирәк: тагын да күбрәк җылылыкка өметләнә бугай ул… Атнаның икенче яртысында бер туганыгыз искиткеч әйбәт хәбәр ирештерер. Керем мәсьәләсендә дә сөенечле яңалыклар ишетелер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Кунак чакыру яки, киресенчә, кунакка бару өчен әллә ни уңайлы чор түгел. Үпкәләүләргә мөмкинсез. Атна уртасында эштә килеп туган хәл үзегезне сәеррәк уйларга этәрер. Ял көннәре бик кызыклы һәм файдалы үтәр.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Мөлаем һәм сөйкемле булуыгызга сокланучылар артыр. Кайберләре хәтта хисләрен дә белдерү җаен табар. Көтмәгәндә генә күптәнге бер танышыгыз белән очрашып күрешү күңелегезне җилкендереп җибәрер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Матди хәлегезнең көтмәгәндә яхшырып китүе кайбер планнарыгызга үзгәреш кертер. Мәсәлән, җәй башында ниятләнелгән чираттагы ялны өйдә генә уздыру теләге туристик сәфәргә чыгу ниятенә алышыныр. Атнаның икенче яртысында күчемсез милеккә бәйле бик мөһим бер мәсьәләнең очы күренә башлар.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Инфекция иярту, салкын тидерү ихтималы бар. Шуңа күрә йолдызлар, май ае булуга карамастан, җылырак киенеп йөрергә киңәш итмәкче. Атнаның икенче яртысында тормышыгызга үзгәреш җиле үтеп керергә мөмкин.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Очрашу-күрешүләргә бай атна. Яңа эш эзләү өчен искиткеч уңайлы чор. Сөйкемле һәм юмор хисенә ия булуыгыз авыр гына мәсьәләне бик җиңел хәл кылу мөмкинлеге бирер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Атна башында берьюлы берничә эшкә тотына күрмәгез – уңышсызлыкка юлыгып, бик уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Гаиләгездә – тәртип. Атна ахырында муллыкка өметләндерердәй бер вакыйга көтелә.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Узгандагы кайбер вакыйгаларны искә төшерердәй хәлләр булып алыр. Күптәнге танышыгызны очратып, әйбәт кенә яңалыклар ишетерсез. Атна ахырында бер яңалыктан мәмнүн калырсыз.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Уйламаганда-көтмәгәндә дигәндәй, гашыйк булып куюыгыз бар. Әлбәттә, гаиләлеләргә саграк булырга кирәктер… Четерекле бер мәсьәләне искиткеч оста һәм җиңел генә хәл итүегез кайбер кемсәләрнең ачуын чыгарыр.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Сак булыгыз: туганнарыгыз белән мөнәсәбәтләрдә шул бер тырмага икенче тапкыр китереп басу куркынычы бар. Хаталар өстендә эш өчен искиткеч әйбәт чор. Моннан тыш җәйге ялга планнар кору өчен дә уңайлы вакыт.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Атнаның беренче яртысында акчага бәйле киеренкелек сизелер. Әйтик, кредит түләү мәсьәләсендә бераз кысынкылык килеп чыгар. Әмма куркасы юк: инде атна ахырында ук яңа керем чыганаклары шәйләнер.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, ире

ГАЛИМУЛЛИН
Рәшит Равил улы

кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документларны эзерләү идарәсе күчермәләр алу-күбәйтү бюросы мөдире Зиновьева Марина Петровнаның авыр кайгысын уртаклаша.

Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы коллективы, энисе

СӘҮБӘНОВА
Минзадә Мингата кызы

вафат булу сәбәпле, директор Сәүбәнова Раушания Кыяметдин кызының, туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӘЙЛӘНӘ БАШЫМ, ӘЙЛӘНӘ...

Баш әйләнү – күпләргә яхшы таныш халәт. Бәхет-шатлыктан гына әйләнсә ярый да. Әмма еш кына баш әйләнү үзәккә үткән афәткә әверелә. Ул 80 төрле чирнең билгесе булырга мөмкин, дип кисәтә белгечләр. Баш әйләнүгә бармак аша карау нәрсәсе белән куркыныч? Аны алдан кисәтеп буламы?

Табиб-терапевт, невролог Эльвина ХАЛИТОВА әлеге сорауларга ачыклык кертте.

:: Эльвина Марсовна, белгечләрнең бер төркеме баш әйләнүне аерым бер чир дип, икенчеләре җитди авыруның бер билгесе дип атый. Сез кайсы фикерне куәтлисез?

– Баш әйләнү – ниндидер җитди авыруның билгесе. Аның ике төре бар. Шуның беренчесе – системалы баш әйләнү. Бу очракта әйләнә-тирәдәге бар нәрсә әйләнә, йөргәндә, башны борганда баш әйләнү тагын да көчәя. Мондый төр баш әйләнү кисәк кенә кан басымы төшкәндә, кисәк торып басканда күзәтелә. Начар ишетү, колак шаулау рәвешендә узган меньера дигән колак авыруыннан интеккән кешеләр дә еш кына баш әйләнүдән зарлана. Системалы булмаган баш әйләнү вакытында кешенең күңеле болгана, күз аллары караңгылана. Мондый халәт, гадәттә, югары кан басымы, анемия, шикәр чиреннән интеккән кешеләрдә күзәтелә. Системалы баш әйләнүне терапевт, кардиолог, эндокринолог дәвалый. Даими баш әйләнүдән интеккән кеше исә неврологка мөрәҗәгать итәргә тиеш.

:: Баш әйләнүнең кайсы төре куркынычрак?

– Системалы баш әйләнү куркынычрак. Ник дигәндә, системалы булмаган баш әйләнү икенчел санала, ягъни ул ниндидер җитди авыруның бер билгесе генә булып тора. Әйтик, гипертония аркасында башы әйләнгән кеше кан басымын контрольдә тотса, баш әйләнүне дә булдырмый кала ала. Шикәр чире, анемия вакытында да шул ук хәл. Күрүебезчә, төп чирне дәвалаган очракта, баш әйләнүне дә кисәтергә мөмкин. Системалы баш әйләнү вакытында исә бу катлаулырак.

:: Машинада барганда баш әйләнүдән зарланучылар да шактый.

– Әйе, бу – шулай ук еш таралган күренеш. Соңгы арада ул күбрәк яшьләр арасында очрый. Даруханәләрдә машинада барганда баш әйләнүне баса торган махсус дарулар сатыла. Кулга махсус беләзек тә тагарга мөмкин.

:: Күпләр баш әйләнүгә, тыныч кына ятып торсаң, үзеннән-үзе үтеп китә торган вакытлы күренеш итеп карый...

– Бу – зур хата. Баш әйләнү борчый башлауга ук кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Вакытында белгечкә күренеп, баш әйләнү белән узган бик күп кенә җитди чирләрне кисәтергә мөмкин. Мисал өчен, кан басымын контрольдә тотмыйча, баш әйләнүгә түзеп яшәү аркасында баш миендәге кан әйләнеше бозылырга мөмкин. Баш әйләнүдән интеккән шикәр чирле кеше комага китәргә мөмкин.

:: Баш әйләнгәндә нәрсә эшләргә ярамый?

– Баш әйләнүдән дә авыр халәт юктыр ул. Авыртуны дару эчеп булса да басып торып була. Теш сызлаганда кулың белән яңакны тотып торсаң да, хәлең бераз җиңеләйгән кебек була. Ә менә баш әйләнгәндә берни дә булышмый. Андый чакта һәр ым, хәрәкәт хәлне авырайта. Шуңа күрә баш әйләнгәндә ятып торырга кирәк. Кисәк тору, утыру, әйбер күтәрү дә тыела. Баш әйләнеп торганда рульгә утыру да хәтәр.

:: Хәлне ничек җиңеләйтергә соң?

– Баш әйләнә башлауга ятарга кирәк. Тәрәзәне ачып куйсагыз да, яхшы булачак. Бүлмәгә саф һава керсен. Ятканда күзегезне бер ноктага төбәгез. Анда-монда карарга, башны борырга ярамый. Күзегезне бөтенләй йомсагыз да була. Ятып торырга мөмкинлегегез булмаса, маңгай тезгә тиярлек итеп бөгелеп утырырга кирәк. Болай эшләгәндә баш миенә кан яхшырак килә башлый. Бу исә кешенең хәлен сизелерлек яхшырта. Баш әйләнгәндә күкрәк тутырып суларга, тирән итеп сулыш алырга тырышыгыз.

:: Баш әйләнүне кисәтү өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

– Баш әйләнү белән уза торган хроник авырулары булган кешеләргә даими рәвештә табибка күренеп, үз хәлен контрольдә тотарга кирәк. Әйтик, кан басымы югары булган кеше аны көнгә берничә тапкыр үлчәп, тикшереп, тиешле даруларны эчәргә тиеш. Шикәр чире, анемия вакытында да күрсәткечләр контрольдә булырга тиеш. Баш әйләнүне кисәтү өчен исерткеч эчемлекләрдән, тәмәкедән баш тартырга кирәк. Каһвә, тоз күләмен дә чикләү зарур. Спорт белән шөгыльләнү, дөрес туклану, йокы туйганчы йоклау да баш әйләнүне кисәтергә ярдәм итә.

pixabay.com

БАШ ӘЙЛӘНГӘНДӘ БУЛЫША



➤100 мл үсемлек маена 30 мл ылыслы эфир мае (пихта, нарат) һәм 10 мл эвкалипт мае кушып, яхшылап болгатыгыз. Аны капкачлы савытка салып, караңгы урында сакларга кирәкле. Баш әйләнгәндә 1–2 тамчы әлеге катнашманы чигәләргә сөртергә кирәк.

➤100әр грамм пион чәчәге тамыры, бөтнек яфрагы белән юкә чәчәген яхшылап болгатыгыз. Ике аш кашыгы катнашманы ике стакан суга салып кайнатырга да төнгә термоска салып калдырырга. Иртә белән шуны сөзеп, көн дәвамында эчәргә кирәк.

➤Кайнар суда төнәтелгән имбир дә баш әйләнүне кисәтергә ярдәм итә.

Киңәш-табыш

ЫЛЫСЫ ДА ШИФАЛЫ

Нарат ылысы – бик күп чирдән дәва. Ул буыннар шешкәндә, бөер авыртканда, балаларда диатез вакытында ярдәмгә килә. Буыннар сызлаганда, кечерәк кенә кәстрүлдәге суга нарат ылысын салып, унбиш минут сүрән суда кайнатып алырга кирәк. Сөзгәч, шушы төнәтмәдән буыннарга компресс куярга була. Диатез вакытында исә баланы шушы төнәтмә белән коендырырга киңәш ителә. Нарат ылысын көзен һәм кышын җыярга кирәк. Бу вакытта ул аскорбин кислотасы, эфир майларына бай була.

БӨЕРГӘ ШИФАЛЫ НАРАТ ТӨНӘТМӘСЕ

Яңа җыелган 50 г яшь нарат ылысын 2 стакан суга салырга, 20 минут кайнатырга һәм 2 сәгать төнәтергә кирәк. Аннары шуны сөзеп, тәменчә бал кушасы. Ылыс төнәтмәсен көненә 0,5 стакан эчәргә мөмкин.

Белеп тор!

Аппетитны ача

Үги ана яфрагы астмага каршы теләсә кайсы даруны алмаштыра ала. Аның төнәтмәсе аппетитны ача, ашказаны-эчәк трактлары һәм сидек юлларының ялкынсыну авырулары вакытында булыша.

Какырыкны куптара

Бу төнәтмә 1 стакан кайнаган суга 1 аш кашыгы вакланган яфрак исәбеннән ясала. Шуны ярты сәгать төнәтәсе. Үги ана яфрагы кайнатмасын да 1 стакан суга 1 аш кашыгы яфрак исәбеннән әзерлиләр. Аны көнгә 3–4 тапкыр, ашаганга кадәр 1–2 шәр аш кашыгы күләмендә эчәсе.



ШПОР БОРЧЫСА

Аяк табанында шпор булган кешегә яңа салынган тавык йомыркасы кирәк. Аны стаканга салып, өстенә 100 г аш серкәсе агызалар һәм катнашманы караңгы, салкынча урынга куялар. 3–4 көн торганнан соң йомырканы серкәдән алып, аның юка элпәсен тишеп, агын агызып алырга кирәк. Ә йомырканың сарысын аерым савытка салып, күбекләнгәнче болгаталар. Аңа 100 г скипидар һәм стакан төбендә калган серкәле утырманы аз-азлап кына куша барып, барысын бергә яхшылап болгатырга кирәк. Әзер катнашманы кара төстәге шешәгә агызып, караңгы урында сакларга.

Кулың нәрсә яшерә?

✱Кулларыгыз даими салкын тора икән, сездә анемия, гипотония, йөрәк чирләре булырга мөмкин.

✱Дымлы куллар организм өчен кирәкле матдәләр бүлеп чыгаручы бизләрнең дөрес эшләмәвен күрсәтә.

✱Кызыл куллар кан басымының югары булуы турында кисәтә.

✱Төшенкелеккә еш бирелүче кешеләрнең куллары аксыл, ә кызу табигатьлеләрнеке кызыл була.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ХУШ, ТӘРӘЗӘ ТӨБЕ!

Яз ахырының суык килүе бакча эшләрен тоткарлый. Ләкин инде шушы араларда халык кыяр, помидор, татлы борыч үсентеләрен тәрәзә төпләреннән теплицага күчерү, ә инде кишер, суган кебек салкыннан курыкмаучы яшелчәне ачык туфракка утырту белән мәш киләчәк. Мул уңыш җыеп алу өчен, бу эшләрне ничек дөрес итеп башкарырга?

Россельхозцентр филиалының үсемлекләрне саклау бүлеге башлыгы Гүзәл ХӨСӘЕНОВА әлеге һәм башка сорауларга җавап табарга ярдәм итте.

pixabay.com

✓ **Теплицадагы туфракны әзерләү.** Күпләр бу эшне күздән үк башкарып куюны хуп күрә. Әмма аны язын да әзерләргә мөмкин. Иң элек, туфракны корткычлардан зарарсызландыру өчен, теплица эчендә күкерт шашкасы яндыру кирәк (1 $м^3$ мәйданга 60–80 грамм күкерт исәбеннән). Үрмәкүч талпаннары күренсә, күкерт микъдарын 150 граммга җиткерергә. Бу эш ишек-форточканы ябып, ярыкларны томалап башкарыла. Шуннан соң теплица стеналарын юып, сөртеп алу зыян итмәс. Ник дигәндә, пычрак стена аша үсентеләргә кояш нурлары начаррак төшәчәк.

Җирен казыганчы, тирес, торф, агач көленнән тыш, туфракны зарарсызландыру һәм үсемлек калдыкларын черетү өчен, «Триходермин Нова» биофунгициды (30 г/1 $м^2$) кертү әйбәт. Туфракны алыштыруга килгәндә, бу – авыр гына түгел, шактый ук нәтиҗәсез эш. Үсентеләр анда барыбер начар үсәчәк. Иң яхшысы – 5–6 елга бер мәртәбә теплицаның урынын алыштыру. Шуңа күрә аны, нигезгә урнаштырмыйча, җиргә генә утыртып куюдан да яхшысы юк.

✓ **Помидор һәм борыч утырту.** Күзен туфракка тирес кертелмичә калса, черемә һәм көл катнашмасы (бер чиләк компостка 1,5 стакан көл исәбеннән) әзерлибез. Помидор утыртыласы чокырларга берике уч шушы ашламаны салып чыгабыз. Кыска сабаклы сортларны рәт арасын – 60 см, үсемлекләр арасын – 30 см калдырып утыртабыз. Озын сабаклылары өчен 70×30 см яки 70×50 см схемасын кулланабыз. Помидор төпләрен черемә, компост яки торф белән мулчәлибез. Үсентеләрне болытлы көндә – төштән соң, кояшлы көндә кичен утырту хәерлерәк булыр.

Утырткканнан соң 10 көн эчендә томат үсентеләренә су сибәргә ярамый, юкса тамырлары зәгыйфь булып, бөтен көчен сабакка бирәчәк.

✓ **Татлы борыч**ка килсәк, салкын туфракны яратмаганлыктан, аны биегрәк түтәлгә (туфракны 25–35 сантиметрга күтәреп) утырту ягын карарга кирәк. Теплица туфрагы зарарсызландырылмаган очракта, үсентеләрне күчереп утыртырга 5 көн кала, туфракка бакыр купоросы эремәсе (10 литр суга 1 аш кашыгы бакыр купоросы) бөркүдән дә яхшысы юк. Туфрак ашланмаган булса, үсенте утыртыласы һәр чокырга берәр уч черемә, чәй кашыгының өчтән бер өлеше күләмендә суперфосфат салып, туфрак белән катнаштырырга, шуннан соң 1–1,5 литр күләмендә алсу төстәге марганцовка эремәсе сибәргә кирәк.

Рәт араларын да, үсенте араларын да 40 сантиметр калдыру борычка бик әйбәт үсү мөмкинлеге бирә.

Шахмат тәртибендә утыртканда, үсентеләрне карау һәм тәрбияләү җиңелрәк булачак.

✓ **Кишер утырту.** Кишер чәчүгә аерым игътибар кирәк. Иң элек орлыкларның сыйфатын тикшерәбез. Моның өчен аларны тозлы суга салып карыйбыз. Төпкә утырганнары – әйбәт, өскә калкып чыкканнары – начар, буш орлыклар дигән сүз. Шуннан яхшыларын яртысәгатькә сыек марганцовка эремәсендә тотабыз. Аннан соң тукыма капчыкка тутырып, туфракка бер көрәк тирәнлегендә 4–5 көнгә күмеп куябыз. Орлыклар шунда үрә башлый. Аннары аларны түтәлгә чәчәсе генә кала. Болай эшләгәндә, кишер бик тиз тишеләчәк. Үрдереп утырту яшелчәне кишер чебененнән дә саклый. Чөнки тиз тишелү нәтиҗәсендә, кишер үсентеләре бөҗәк личинкалары котыра башлаганчы ук ныгып калачак.

Үзем сынадым

КИШЕР ЧӘЧҮ ХӘЙЛӘСЕ

Орлыкны буразнага сипкәндә, нык иелеп эшләү билгә бәрә. Моннан котылу өчен, мин болай эшлим. Суга бераз крахмал салып, сыеграк итеп кесәл ясыйм. Шуны икешәр литрлы ике пластик шешәгә тутырам. Һәркайсына 2шәр пакет кишер орлыгы салам да, орлыклар сыекчада тигез таралсын өчен, шешәне яхшылап селким. Шуннан, шешә капкачына тишекләр ясап, орлыклы сыекчаны буразнага сибәм. Орлык төпкә утырмасын өчен шешәне әледән-әле селкеткәләп торырга кирәк. Болай эшләгәндә, кишер бик тигез, әйбәт тишелә һәм бил дә авыртмыйча кала.

Ольга МАКАРОВА.
Балык Бистәсе

«Шәрә» борыч

Әйбәт уңыш алу өчен, татлы борыч үсентесе яфракларын өзеп торырга кирәклеген беләсезме икән? Үзем инде күп еллар буе шулай эшлим. Үсентеләрне май урталарында ачык туфракка күчерәм. Ике атна дәвамында өстен каплап тотам. Шул ук вакытта, акрынлап кына урам һавасына һәм җилгә ияләшсен өчен, ике башын ачып куям. Үсемлек чәчәк ата башлагач, чәчәкләре тагын да күбәйсен өчен, бер рәт аскы яфракларын өзеп ташлыйм. Борычлар яралгач, тизрәк үссеннәр өчен, астан икенче рәт яфракларын кыркыйм. Ә инде өлгерү билгеләре күренгәч (борычлар сары яки кызгылт төскә керә башлагач), сабакта бер яфракны да калдырмыйча өзеп бетерәм.

Альберт НӘҖМЕТДИНОВ.
Казан

Тәмле булсын!

Өй кефиры

Әлфия СӨЛӘЙМАНОВА рецепты

Кирәк булачак: кайнатып, 45 градус чамасына кадәр суытылган сөт.

1 литр сөткә ярты аш кашыгы кибет кефиры салабыз. Банканы сөлге белән каплап, җылы җирдә 8–10 сәгать тотабыз. Шуннан соң суыткычка алып куябыз.

Телеңне йотарлык кефир килеп чыга!

КЫЧЫТКАН АШЫ

Гөлнур МОСТАФИНА рецепты

Май кычытканыннан да файдалырак үсемлек юк, ди табиблар. Шуңа күрә бу айда һич югы 2–3 тапкыр кычыткан ашы пешереп ашарга киңәш итә алар.

Кайнап торган суга бераз кыздырылган фрикаделька, бәрәңге, кишер һәм суган салабыз. Пешеп җиткәндә, туралган кычыткан, 2 йомырка туглап, шулпага болгата-болгата өстибез. 1–2 минут кайнаткач, сүндерәбез.

Белсән, зыян итмәс

Чәчәк сайлау серләре

Кибеттәге чәчәкнең кайсы яңа гына өзелгән булуын бер сатучы да әйтмәячәк. Моны танып белү өчен, түбәндәгеләргә игътибар итегез.

▶ **Роза.** Яңа гына өзелгән розаларның касә яфракчыклары өскә карап тора, сабагының киселгән очы ап-ак, яфраклары ялтырап тора, бөреләре каты була. Бөреләре ачыла башлаган һәм йомшак икән, димәк, гөлчәчәк инде байтактан кибет тузанын йотып утыра дигән сүз.

▶ **Алтын чәчәк (хризантема).** Чәчәк уртасындагы «төймәчек» беркайчан да кара төстә булмаска тиеш. Каралган булса, димәк, «күпне күргән» дигән сүз.

▶ **Лалә.** Ботагында 1–2се генә ачылып, башлыча бөредә утырганнарын сайлап алырга кирәк. Бөреләренең төсе яшел булырга тиеш. Сары икән, беркайчан да чәчәк атмаячак.

▶ **Канәфер.** Сабагында аркылы сырлар булмаска тиеш. Бу очракта бөреләре ачылмаячак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ХАТЫННАРГА ГАДЕЛЛЕК КИРӘК

Җәмгыятьтә әледән-әле күпхатынлылыкка бәйле сораулар туып тора. Исламда бу чикле күләмдә рөхсәт ителгән гамәлләрдән санала. Бер казанга ике тәкә башы сыя алмый, ди халык. Ә гаиләдә хатыннар бердән күбрәк булса, ничек яшәргә? Гомумән, берничә хатын алырга теләгән ир-атларга нәрсәне истә тотарга? Хатын-кызга исә көндәше белән ничек яшәргә?

Кызыксындырган сорауларга «Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ җавап бирде.

:: Рөстәм хәзрәт, пәйгамбәрләр дә, күп хатын белән яшәсәләр дә, бердән артыгын ярата алмаган. Шулай булгач, ни өчен исламда күпхатынлылык рөхсәт ителә?

– Халыкта «ислам дине хатыннар санын арттырган» дигән бер фикер яши. Тарихка күз салсак, киресенчә, ислам дине хатын-кызлар санын киметкән һәм чикләгән ул. Гарәпләрдә җаһилият (ислам динен кабул иткәнче булган заман. – **Авт.**) чорында унар хатын белән яшәгән кешеләр булган. Ислам диненә күчкәч, пәйгамбәребез (с.г.в.) аларга: «Хатыннарыгызны дүрткә кадәр генә калдырыгыз», – дип әйткән. Коръәннең «Ән-Ниса» («Хатыннар») сүрәсенең 3 нче аятендә: «Хатын-кызлардан күңелегезгә хуш килгәнен үзегезгә никах кыйп алыгыз: икене, өчне һәм дүртне», – диелә. Әгәр дә алар арасында гаделлек булдыра алмыйм дип куркысагыз, берсенә генә өйләнү хәерле, ди.

Әйе, хәтта пәйгамбәребез (с.г.в.) дә Гайшә анабызны күбрәк яраткан. Ягъни бу – Аллаһы Тәгаләдән. Кеше барлык кешене дә бертигез ярата алмый. Гаиләдә дә балалар арасында эти кеше гаделлек урнаштырырга тиеш бит. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Аллаһтан куркыгыз, балаларыгыз арасында гадел булыгыз», – ди. Ягъни берсенә бүләк аласың икән, икенчесенә дә тиешле. Алар арасында хөсетлек, ызгыш чыкмасын өчен, тигез күрү хәерле.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кемнең ике хатыны булып, алар арасында гаделлек урнаштыра алмаса, Кыямәт көнендә бер ягы фалиҗ булыр», – ди. Димәк, өйләнү – түгел сөйләнү. Бер хатынга өйләнү дә зур җаваплылык булса, күпхатынлы булу – тагын да зуррак җаваплылык.

Күпхатынлылык булган җәмгыятьтә зина булмый. Менә шунысын аңларга кирәк. Балалар әтиле үсә. Гаиләнең яклаучысы була. Аналары ялгызы гына тәрбияләгән балалар, ир малайлар барлыгын беләбез. Андыйлар үзгәрәк була. Иркәрәк алар. Чөнки хатын-кызда үз җылысын, назын бирү сыйфаты бик зур. Аллаһы Тәгалә аны шулай яраткан. Ә артык күп наз күргән малай «әни малае» була, аңа үз тормышын кору да җиңел булмый. Аның яшәеше «мин – ир кеше, мин тиеш бит» дигән фикерләрдән азат. Альфонслар шуңа арта инде. Егетләр, килен төсле, йортка төшә. Ә ир-егет өйләнергә, ягъни «өйле» булырга тиеш. «Ир-ат» дип тә юкка әйтелми. Ир кеше гаиләсен алып барырга, кайгыртырга, чабарга, гаилә йөген тартырга тиеш. Элек эш аты берәү генә булган, хәзер икәү. Икесе дә эш аты булгач, һәркайсы үзенекен даулый. Гаиләләрдә низаглар арту да шуңа гаҗәп түгел.

:: Алайса, ни өчен хатын-кызларга күпирлелек рөхсәт ителми?

– Непал дигән илдә күпирлелек гадәте бар. Ләкин Аллаһы Тәгаләнең диненә бу гадәт хас түгел. Аның сәбәпләре дә күп. Әгәр дә хатын-кыз берничә ир белән яши икән, аннан туган бала кайсы ирдән, кемнеке икәнен кем белеп бетерер? Исламда нәсел дигән төшенчәгә җаваплы карыйлар.

:: Күпләр күпхатынлылыкны дөрес аңлап бетерми бугай. Аның таләп-шартларын аңлатсагыз иде. Бу бит – яратуны, хисләрне, мал-мөлкәтне бертигез итеп, гадел дәрәҗәдә бүлү дигән сүз дә.

– Халык, кызганыч, Аллаһы Тәгаләнең аятьләренә, гади итеп әйтсәк, ревизия ясамый. «Ни өчен болай әйтелгән? Нигә шулай икән?» – дими. Кызганыч, кешеләр, үзләрен белдекле санап, кайвакытта дин әһелләре белән сүз көрәштерә. «Моның белән килешмибез, диннең бу өлеше дөрес, монысы дөрес түгел», – дип, бәхәскә керергә яраталар. Сорау бирү тыелмый, тик Аллаһы Тәгаләнең аятен укыганда, дөрес фикерләргә кирәктер, укымавым сәбәпле, аның ни

Илдар Мөхәммәтҗанов

әйтергә теләвен аңлап бетермимдер дип шикләнергә буладыр.

Гаделлек дигәндә, хисләрне тигез итеп бүлеп бетереп булмыйдыр да. Бүләк бирү, вакыт ягыннан тигезлек саклау, тәэмин итү ягыннан тигезлек кирәк. Хатын-кызның нәфакага (иждивение. – **Авт.**) хакы бар. Ягъни ир кеше хатынын йорт-җир, кием-салым, азык-төлек белән тәэмин итеп торырга тиеш.

:: Хатын-кызларга нинди киңәш бирергә була? Көндәш белән бер йортта тору җиңелләрдән түгелдер...

– Билгеле, сабырлык. Ләкин бер йортта тору җиңел булмаганын белеп, динебездә пәйгамбәребез (с.г.в.) гүзәл затларыбызны бер түбә астында тотуны тыйды. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хатыннары да бер өйдә тормаган, аларның һәркайсының үз йорты, үз бүлмәсе булган.

Күпхатынлы ирләргә җиңел түгел. Күпләр: «Фатир алам да, барысы да бер түбә астында яшәрләр, кая барсыннар», – дип уйлыйдыр. Алай дөрес түгел! Үзләре моңа риза булса гына. Һәркайсы аерым фатир кирәк ди икән, ир-ат аны тәэмин итәргә тиеш.

:: Ә сөяркә тоту күпхатынлылыктан саналамы?

– Сөяркә булу – зина. Аның өчен – үлем җәзасы. Олы дәрәҗәдәге җинаять бу. Махсус рәвештә башка кешене үтергән, мөртәт булган, зина кылган кешеләргә исламда үлем җәзасы каралган. Әлбәттә, бездә бу үтәлми. Моның куркыныч гамәл икәнен онытмыйк! Ислам шуңа да аны тыя. Зинаны гына түгел, аңа алып барган сәбәпләрне дә. Коръәндә: «Раббыбыз хыянәт кыла торган күз карашларын да белә», – диелә. Хәтта ки урамнан узып баручы хатын-кызларга ир-атларның каравы да тыелган.

:: Балалары булмаган очракта, хатын иренә башка хатын табып биргән очраклар да юк түгел. Бу диндә рөхсәт ителәме?

– Әйе, хатын бүтән хатын табып бирергә мөмкин. Мондый практика бар. Хатын иренә кем кирәген яхшырак та беләдер. Аның өчен, билгеле, хатын-кызга бик тәкъва булу кирәктер. Ир кешегә дә алай җиңелрәк инде, сүз дә юк.

:: Яшерен никахлар да бар бит әле, хәзрәт. Хатыны иренең башка хатыны барлыгын белмичә яшәүләре ихтимал. Бу рөхсәт ителәме?

– Тыела. Никах кимендә ике мөселман ир яисә бер мөселман ир һәм ике мөслимә хатын-кызның шаһитлар булуы белән генә укыла ала. Кайвакытта шаһитлар саны җитеп тә, никахын беренче хатынына белгертмәгән ирләр бар. Бу никах дөрес санала. Аллаһы Тәгалә каршында кабул ителгән никах ул. Әмма гаделлек саклау ягыннан караганда, икенче хатын беренчесе турында белгән кебек, беренчесе дә икенчесе турында белеп торырга тиеш.

Белеп тор!

Хикмәтле кабак

Кабак турында менә шушындый хәдисләр билгеле. Бу инде әлеге яшелчәнең никадәр файдалы һәм хикмәтле булуын дәлилли.

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе: «Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кабакны ярата иде», – дип әйткән.

Җәбир бине Тарикъ Әл-Әхмәси әйткән: «Бервакыт мин Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам янына кердем һәм анда кабак күреп, аннан: «Бу нәрсә?» – дип сорадым. Ул соравыма: «Без аның белән үз ризыгыбызны арттырабыз», – дип җавап кайтарды».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйтә торган булган: «Йә Гайшә, ризык әзерләгән вакытта син аңа күбрәк кабак сал, чөнки ул сагышлы йөрәкне ныгыта!»

Әбү Талут радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мин Әнәс бине Мәлик янына кердем. Ул:

«Аллаһының Илчесе яратып ашаганга күрә, син миңа бик кадерле ризык», – дип әйтә-әйтә кабак ашый иде».

Йәгез, бер дога!

МАЛ ХУҖАСЫН ТЫҢЛАМАГАНДА УКЫЛА

«Бисмилләһир-рахманир-рахим.
Ә фәгайра динил-ләһи йәбгунә үә ләһү әсләмә мәң фис-сәмәүәти үәл-әрдый тауґәү үә кәрһәү үә иләйһи йүрҗәгъүн».

Мәгънәсе: «Мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһы Тәгалә исеме белән башлыйм.
Әллә алар Аллаһ диненнән башка дингә омтылалар микән, күктәгеләр һәм җирдәгеләр ирекле һәм ирексез рәвештә Аңа бирелгәннән соң һәм сез Аңа кайтарылачак чакта?»
(«Әл-Гыймран» сүрәсе, 83 нче аять)

Ибн Габбас китергән хәдис:
«Әгәр терлегегез тыңламый башласа, аның колагына әлеге доганы укыгыз».

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЭЛЬВИРА ФАЗЛЫЕВА:

«ЯҢА ТОРМЫШ БАШЛАРГА ВАКЫТ ҖИТКӘНДЕР»

Тормышы – җырында. Ул күргән кайгы-хәсрәтне җырчының иҗатын күзәтеп баручылар да кичерде. Ике ел элек кызын югалткан Эльвира ФАЗЛЫЕВА бүген яңа тормыш корырга тырыша.

:: Ни хәл?

– Аллага шөкер. Алга карап яшәргә тырышам. Концертларда катнашкалыйм. Әле менә җырчы Динара Рәхимованың концертларында махсус кунак буларак чыгыш ясап йөрим. Яңа җыр әзерлибез.

:: Күптән түгел сезгә тәкъдим ясадылар. Котлыйбыз! Булачак тормыш иптәшегез белән ничек таныштыгыз?

– Безнең танышуга да нәкъ менә Динара сәбәпче булды. Озак очрашып йөрдек, дип әйтә алмыйм, ләкин бер күрүдә үк күңелемә якын кеше булып тоелды ул миңа. Тәкъдимне исә көтмәгәндә, уйламаганда ясады. Шулай да риза булдым. Бу адымын изге рамазан аенда ясавына бигрәк тә сөендем.

:: Яңа мөнәсәбәтләр башлау кыен булмадымы?

– Мөнәсәбәтләр бит әле башланып кына килә...

:: Тормышыгызның яңа этабы башлана, дип әйтә аласызмы?

– Шулай буласына ышанасым килә. Газапларны күп күрергә туры килде, алга таба атларга, бәхетле яңа тормыш башларга вакыт җиткәндер.

:: Аиданың әтисе Александр белән сез нинди мөнәсәбәттә?

– Бала хәсрәте араларыбызны суытты шул...

:: Кызыгызны сагынмаган көнегез юктыр... Бу яра белән яшәргә ничек өйрәнәсез?

– Мондый хәсрәтне үз башыннан кичергәннәр генә аңлар. Кызымны ике ел элек югалттым. Аның чын күңелдән елмаюын, матур итеп көлүен, шаяруларын, «Әни, мин сине яратам!» – дип әйтүләрен көн дә сагынып искә алам. Бу куркыныч төш кайчан да булса тәмамланып, уянырмын да янә Аидамны кочагыма алырмын сыман. Ләкин бу төш түгел, бу – чынбарлык. Кызганыч, үткәннәрне кире кайтарырлык көчем юк шул. Миңа кырыс чынбарлыкны кабул итеп, алга таба яшәргә генә кала...

Блиц-сораштыру

– Хисләрегезне җырга саласыз. Сезнең өчен җыр – нәрсә ул?

– Күңелемә юаныч.

– Иң бәхетле көнегез?

– Кызым Аида туган көн.

– Бүген хатын-кызга бәхетле булу өчен нәрсә җитми?

– Бүген хатын-кыз артык көчлегә әйләнде. Алар янында ир-егетләр, киресенчә, көчсез булып күренә. Минемчә, һәркем үз урынында булырга тиеш. Көчле ир-егет янында хатын-кыз үзен бәхетсез димәс, мөгаен.

– Сезне чыгырдан чыгара торган күренеш?

– Ялган, хыянәт һәм гаделсезлек.

:: Авыр чакта иң зур терәгем әти-әнием булды, дигәнсез бер әңгәмәдә. Алар биргән иң кадерле киңәш нинди булды?

– Әти-әнием дә минем белән бергә кичерделәр бу хәлләрне. Беләм, аларга икеләтә авыр. Аида да аларны бик яратты, «әбием», «бабаем» гына дип торды. Озак көрешми торсалар, төннәрен сагынып елый иде.

Җәлилчеләр соңгы юлга иманлы булып киттеләрме икән? Муса Җәлилнең туган көнендә аның һәм Ильһам Шакировның (алар икесе бер көнне туган) рухларына Коръән уку мәҗлесендә бер кунак шул сорауны бирде. Шундук сорауга җавап бирүче дә табылды. Муса Җәлил музей-фатирының өлкән фәнни хезмәткәре Нәзирә Фәттахова янәшәбездә булып чыкты. Форсаттан файдаланып, ул безгә герой-шагыйрь турында шактый мәгълүматлар бирде. Җиңү көне уңаеннан аларны укучыларыбызга җиткерүне дә кирәк дип таптык.



Коръән китабы

– Музейга килүчеләрдә, чыннан да, Коръән китабы аерым бер кызыксыну уята. Ул зур түгел. Үлчәме 9 сантиметрга 12,5 см. Барлыгы 876 бит. Кәгазе бик юка. Һәр битендә махсус нәкыш-бизәк. Беренче биттә «Гани Госман Симипулат – Берлин» дигән мөһер бар, ул тагын ике урында кабатлана әле. Коръән китабы шушы кешенеке булган. Ул Бөек Ватан сугышы вакытында Берлинда «Татар комитеты»нда мулла вазыйфасын башкарган. 1944 елның 25 августында, җәлилчеләрне җәзалап үтерергә бер сәгать кала, Гани Госман аларның камерасына керә. Җәлилчеләрнең һәрберсе шушы Коръәнгә кулларын куеп, якты дөнья белән бәхилләшә. Муса Җәлилнең Коръәнгә иң соңгы булып кулын куюы мәгълүм.

> Бу китапны, изге хатирә-истәлек итеп, Америка Кушма Штатларында яшәүче эмигрантлар саклаган. Казанга ул Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае көннәрендә килеп ирешә. Дөресрәге, академик Миркасыйм ага Госманов аны беренче тапкыр Америкада күрә. Хуҗасы белән китапны корылтайда тантаналы төстә тапшыру турында килешәләр. Ләкин бу ният ниндидер сәбәпләр белән барып чыкмый. Миркасыйм ага музейга аны үзе тапшыра. Китап Дәүләт музее фондында саклана.

Моабит дәфтәрләре

Музей барыннан да бигрәк бөтен дөньяга билгеле Моабит дәфтәрләре белән горурлана. Шагыйрь бу циклга кергән шигырьләрне 1942–1944 елларда фашист төрмәләрендә язган. Безнең көннәргә ике дәфтәр килеп ирешкән. Беренчесе – 9,5х7,5 см үлчәмендәге куен дәфтәре каралы карандаш белән язылган 60 шигырьне үз эченә ала. Тышлыкта «1943 ел» дип язылган дата күрсәтелгән. Аның янәшәсендәге язма сызылган-бозылган, ләкин зурайткыч пыяла аша Габбас Шәрипов дигән исемне (дәфтәрне Моабит төрмәсеннән алып чыккан кеше) укып була. Шушында ук шагыйрь кулы белән немец телендә «Немец, төрки, рус сүзләренең һәм әйтелмәләренең сүзлеге» дип язылган. Бу текст астында гарәп язуы белән татарча «Муса Җәлил. Шигырьләр һәм сүзлек» дигән сүзләр теркәлгән.

Икенче блокнот – кулдан ясалган куен дәфтәре. Кәгазе тыгыз түгел, соры төстә. 10,7х7,5 үлчәмендә. Монда – 50 шигырь. «Жена Сейфуллина Нина Константиновна (Амина) г. Москва, 25, Столешников пер. Д.11кв1» дигән язу бар. Дәфтәргә латин шрифты белән татарча «Бу төптә – 33 шигырь. Әсирлектә һәм тоткынлыкта 1942-IX-1943-XI арасында язганнарым – 125 шигырь һәм поэма. Ләкин кая языйм? Үзем белән бергә үләләр. М.Җәлил» дип тә язылган. Немец телендәге язу да бар: «Яраткан дустым Андре Тиммерманска Муса Җәлилдән 1943-44 Берлин».

Нәкъ менә бельгияле Андре Тиммерманс дәфтәрне саклап калган һәм сугыштан соң Брюссельдәге совет илчелегенә тапшырган. Бу дәфтәр эченә 17 яңа шигырь язылган кәгазь битләре дә салып куелган. Соңгы шигырь 1944 елның 1 гыйнвары белән даталанган. Язулар каралы һәм гади карандашлар белән язылган. Ике дәфтәрдә шагыйрьнең барысы 110 шигыре урын алган, ләкин аларның 17се кабатлана.

Бүген дәфтәрләр махсус саклауда торалар һәм елга бер тапкыр шагыйрьнең туган көнендә генә күрсәтеләләр.

Андре Тиммерманс

Бельгиягә халыкара поэзия фестиваленә баргач, совет шагыйре Константин Симонов Андре Тиммермансның язмышы белән кызыксына. Һәм аны Брюссельдән 40 км чамасы ераклыктагы Тирлемон шәһәреннән эзләп таба. Андре аңа герой-шагыйрь турында шактый мәгълүмат бирә.

...Немецлар Андрены камерага алып килгәндә, Җәлил анда була инде. Аларга еш кына икәү бергә калырга туры килә. Андре – французча һәм бераз гына немецча, ә Муса Җәлил рус һәм татар телләрен генә белгәнгә, аңлашу бик кыен була. Рәсемнәр ярдәмендә аралашалар. Андре күршедәге ике камерада – үнда һәм сул якта – тагын ике татар утырганын хәтерли. Берсе – Булатов, икенчесе – Алишев. Эш өчен аларга берничә инструмент, шул исәптән кечерәк кенә ясы өтерге бирелә. Шул өтерге белән стенаны тишәргә тотыналар. Прогулкага чыккан саен, таш валчыкларын учларына җыеп, төрмә ишегалдына кеше сизмәслек итеп әз-әзләп кенә чәчеп калдыралар. Ниһаять, тар гына тишек тишелә. Шул көннән Җәлил Булатов белән сөйләшү бәхетенә ирешә. Берничә көннән ниен икенче якка тишек тишә башлыйлар. Ләкин эшне азагына җиткерә алмыйлар: Җәлилне Дрезденга судка алып китәләр. Ул яңадан кайтмый, ләкин Андре аны соңрак Шпандаудагы төрмәдә күрә. Ул бу хакта менә ничек сөйли: «Иртән, төрмә ишегалдында йөргәндә, мин тавыш ишеттем. Кемдер игътибарны үзенә җәлеп итәргә тырыша иде. Шактый вакыт як-ягыма каранып йөрдем, ләкин беркемне дә күрә алмадым. Бер көн үткәч, бу тавышны янә ишеттем. Төрмәнең аскы кат тәрәзәләре чагыштырмача түбән урнашканнар һәм, тар гына ярык калдырып, әчкә таба ачылалар иде. Мин кинәт әнә шул ярыкта Җәлилнең башын күреп калдым, дөресрәге, бөтен башын түгел, ә битенең бер өлешен генә – чөнки ярык бик тар иде. Бер тапкыр әйләнеп үткәч, тагын теге тәрәзә белән тигезләндем һәм, ботинкамның шнурын бәйләгән булып, аска иелдем. Бу минутта Җәлилнең үзен күрмәсәм дә, тавышын ишеттем. Ул пышылдап кына суд булуын һәм башын кисәчәкләрен җиткерде.

Минем аның белән күрешәсем, сөйләшәсем килде. Җәлил торган баштагы тоткыннарның ниндн көнне душка йөргәннәрен белергә тырыштым. Юынган арада ун минут буена сөйләшеп тордык. Җәлил шунда үзенең һәм татар иптәшләренең үлем җәзасына хөкем ителүләрен әйтте».

Шул күрешүдән соң Андре Җәлилне башка күрми. Берничә көннән аның үзен Луккау шәһәрендәге лагерьга күчерәләр.

Ә дәфтәрне Җәлил аңа Дрезденга судка җибәрүдән ярты ай элегрәк, үзен җәзалап үтерәчәкләренә төшенгәч тапшыра. Исән-сау өенә кайтып җитә алса, совет консуллыгына тапшыруын үтенә. Соңрак китапның язмышы түбәндәгечә була.

– Шпандауга күчергәндә, мин аны үзем белән алдым – киемнәрем эченә яшердем. Биш ел каторгага җибәрү турында яңа хөкем карары игълан ителгәч, төрмә конторасына барып, артык әйберләремне тапшырырга тиеш идем. Җәлилнең дәфтәрен башта ук күзгә ташланып тормаслык, ләкин шул ук вакытта махсус рәвештә яшергән дигән фикер тумаслык итеп, әйберләрем арасына тыктым. Аның белән бергә Берлин төрмәсендә немец рухание биргән догалык китабын да салдым. Аның беренче ике битендә Җәлилнең миңа бүләк итеп язган шигырьләре бар иде. Немецлар: «Нәрсә бар анда?» – дип сорагач, көндәлек, дидем. Бәхеткә, дәфтәрдәге язуның бөтенләй башка бер телдә икәнлегенә игътибар итмәделәр.

> Андреның әйберләре, догалык һәм Җәлил дәфтәре салынган посылканы әнисенә җибәрәләр. Төрмәдән концлагерьга күчергәндә, хат язарга рөхсәт итәләр. Ул анда дәфтәрне һәм догалыкны ничек тә булса сакларга кирәклеген аңлата. Тик ул кайтканда догалык юкка чыккан була. Бик каты авырып китү сәбәпле, дәфтәрне дә вакытында тапшыра алмый. Брюссельдә булгалый торган бер иптәше аның үтенече буенча дәфтәрне совет илчелегенә илтеп тапшыра.

Саубуллашканда Константин Симоновка ул мондый сүзләр җиткерә: «Муса Җәлил бик тыныч һәм батыр кеше иде. Мин ул дәфтәрнең андый искитәрлек нәрсә икәнен белмәдем дә. Бары тик иптәшемнең үтенечен генә җиренә җиткердем».

Бу гади, тыйнак сүзләр артында Андре Тиммермансның батырлыгы ята: ул – әдәбият өчен Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрен коткарып калган бөек кеше.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ

Балтач районының Арбор авылында яшәүче Фәннур Әүхәдиевне авылдашлары әнә шулай дип искә ала хәзер. Мәкерле авыру белән көрәшеп тә, актык айларына кадәр аны бирәүгә дә сиздермичә, зарланмыйча 51 яшен тутырып, арабыздан китте ул. Ураза аеның соңгы көннәрендә, иман кәлимәсен китереп, күзләрен мәңгелеккә йома Фәннур абый. Аны озатканда ирләр дә елый хәтта.

Әле кайчан гына күрешеп сөйләшкән идек. Аңа кадәр телефоннан сөйләшкәләдек. Ярдәм кирәклеген белгәч, мин аңа үзем шалтыраткан идем. «Әйдәгез, сезнең хакта газетага язып чыгыйк. Укучыларыбыз ярдәм итәр. Операциягә акча җыярбыз», – дидем. Ә ул исә: «Бер дә кешеләрдән ярдәм сорыйсым килми шул. Ничек тә акча табып булыр әле. Ясата алмасам, димәк, шулай язган миңа», – диде.

Фәннур абыйның язмышы җиңелләрдән булмаган. Биш яшендә әтисез калган. Укуын бетергәч тә, ул авылны сайлаган. Мәктәпне тәмамлаганда, механизатор «права»сы була, шуның белән ул машина паркына эшкә килә. Армиядән кайткач, сөйгәне Гөлнур белән гаилә корып җибәрә. Тормышларын ямьләндереп, башта уллары Раннур, аннары кызлары Гөлгенә туа. Әйбәт кенә гомер итәләр. Фәннур абый бик тә матур итеп җырлый да әле. Аны кая гына чакырмыйлар. Үзе дә күп кенә бәйгеләрдә катнашып, җиңү яулый. Авыл халкы аны «үзебезнең Салават» дип йөртә. Гел җырлап йөри ул. Тик матур тормышларына күз тия. 2005 елның 2 маенда Фәннур абый, тракторына культиватор тагып, туфракка аммиак кертә. Кечке якта кабина артына урнаштырылган аммиак багы шартлап, аның өстенә сыек аммиак түгелә. Күзләренә шунда зыян килә. Аның дөньясы караңгылана.

– Әтием ике айга якын Республика клиник хастаханәсендә дәваланды. Аның бар тәне төзәлде, сызланулары бетте. Әмма күзләре ачылмады. Күзләре күрмәсә дә, исән калуына сөендек. Без әтием белән бер-беребезне ярты сүздән аңлый идек. Икебезгә бер җан кебек булды. Бар серләремне аңа сөйләдем. Әтиебез күрмим дип тормады, үзенең көчле рухлы икәнен күрсәтте. Ул беркайчан да күңелен төшермәде. Күрә башлыйсына ышанды, – ди кызы Гөлгенә.

Дөньяны яңадан күрергә 10 ел кирәк була. Аңарчы кая гына барып карамый ул. Чабаксар, Уфа, Казан табибларына күренә. Ә менә Мәскәүнекеләр ясаган операция уңышлы килеп чыга. Фәннур абый күрә башлый! Инде ул чакта кечкенә сабыйлары зур үскән була! Ул сөенеп туя алмый. Дөньяны тагын да яратып яши башлый. Тик күзләре биш ел гына яхшы күрә. 2021 елда авыру тагын үзен сиздерә. Табиблар яңадан операция кирәклеген әйтә. Бушлай ясаганнарын озак көтәсе булгач, алар түләүле клиника сайлый. Күзләрен тикшерткән вакытта, Фәннур абыйда яман чир барлыгы ачыклана. Баштарак моңа ышанмыйлар да. Кат-кат тикшерелә торгач, мәкерле авыруның барлыгын төгәл әйтәләр. Чир үпкәләренә зыян сала...

Яшәренә өмете зур иде аның. Казан хастаханәсенә дә үзе килеп күренеп йөрде. Табибларга һәм Аллаһы Тәгаләгә ышанды. Тереләсе, кызының, улының туйларында йөрисе, оныклар сөясе килде. Гөлнурын да калдырып китәсе килмәде. Авыру белән соңгы көненә кадәр көрәште. Хәлен сорагач та, түзәрлек, дип җавап бирә, бер дә зарланмый. Урын өстендә дә җырлап ята. Әмма үлемен сизә кебек. Хәлен белергә килүче авылдашларына, мин сезне чәчәкләр тотып каршы алырмын, дип тә әйтә. Иң зур теләге – рамазан аенда бакыйлыкка күчү була. Һәрвакыт догада була ул. Соңгы көннәрендә гаиләсенең, дүрт туганының җылысын тоеп яши. Апалары, абыйсы, сеңлесе янынннан китми.

Инде ашларын да уздырдылар. Бар авылдашлары аны мактап искә ала. «Ул азан әйткәч тә, авыл өстендә аның тавышы ишетелеп торгандай булыр иде», – диләр. Коръәнне дә моңлы итеп укыган. Яхшы күңелле, көчле рухлы икәнен дә искә алалар. Кыска гына гомерендә бар әйбергә дә өлгергән ул. Эшен дә эшләгән, сәхнәдән дә төшмәгән, дингә килеп, ислам кушканча да яшәгән. Үзеннән соң кул күтәреп дога кылучылары да бар. Улы Раннур әнә әтисе кебек бөтен авылны моңга күмеп азан әйтә хәзер. Гөлнуры күз яшен күрсәтми генә еласа да, сабыр итә. Кызы исә әтисез яшәргә өйрәнә...

ЯШӘП КАЛАСЫ КИЛӘ!

Теләче районының Үзәк авылында гомер итүче 35 яшьлек Мария Шаронова инде берничә ел кислород аппараты ярдәмендә сулый. 2014 елда аңа башка кешенең үпкәләрен күчереп утырмакчы булганнар, тик дәвалаучы табибы бу уйдан кире кайтара. Хәзер Мария һәр туган көнгә шөкер итеп яшәп ята.

– 17 яшемдә укырга керү өчен медицина тикшеренүе узганда, үпкәмдә тап күреп алдылар. Шуннан соң каткат тикшерделәр. Башта туберкулез дигәннәр иде. Аннары онкология хастаханәсенә җибәрделәр. Тик төгәл диагноз куючы булмады. Ахыр чиктә, туберкулез дигән фикергә килеп, шул чирдән дәваладылар. Күп итеп дарулар да эчтем, санаторийларга да йөрдем, – дип искә ала Мария.

Баштарак авыру үзен бик белгертми. 2010 елда кияүгә чыгып, бала алып кайтканнан соң, тыны кысыла башлый. Башта ул моны көннең эсселегенә бәйли. Тик хәлсезлек, һава җитмәү еш кабатлана. Мария тагын хастаханә юлын таптый башлый.

– Ул вакытта энем дә үлде. Бик каты борчылдым. Әллә стресс ярамады инде, бөтенләй начарайдым. Казан табиблары мине Мәскәүгә җибәрде. Киткәндә, дәвалаучы табибым: «Синдә фиброз, ахры», – дигән иде. Тикшерелә торгач, диагноз расланды. Әле шуңа өстәп, тузанга, күгәреккә аллергия, диделәр. Үпкә күчереп утырмасаң, озак яшәмәячәксең, дип кайтарып җибәрделәр. Алты айдан соң, барысын да яхшылап уйлап, операциягә килергә куштылар. Мин инде бармакчы да идем. Тик Казандагы табибым: «Чит кеше үпкәләре белән озак яши алмыйсың син», – дип туктатып калды, – ди Мария. – Хәзер аңа рәхмәт укыйм. Шөкер, авырлык белән булса да, яшим бит әле мин!

Чынлап та, Мария һәркөнне яшәр өчен тырыша. Иртән торгач, үпкәләре тиз генә эшләп китми икән. Ул бик тә тилмерә, көчле өянәкләре була. Уңайланып киткәнче, шактый түзеп тора. Әле ярый, янында ире бар. Мария үзе генә түгел, авылдашлары да Игорьга рәхмәт укый. Әле шушы көннәрдә генә редакциягә бер ир-ат шалтыратты. «Сез газетага төрле язмышлы кешеләрне язасыз, менә безнең авылда яшәүче Шароновларны да кешегә күрсәтергә кирәк. Хатыны түгел, балалары авырса да, ир ташлап кача. Ә Мариянең ире шулкадәр кадерләп, саклап яшәтә. Бик күпләргә үрнәк», – диде ул абзый.

Без Мария белән ире хакында да сөйләштек. Аның турында сүз башлагач, ул еларга ук тотынды.

– Безнең улыбыз бар. Владикка тиздән 12 яшь тула. Нинди генә авырлык күрсәк тә, гаиләбез нык, бер-беребезгә хөрмәт зур, – ди Мария. – Мин бит инде гомерем буе хастаханә юлын таптыйм. Ирем авыру икәнемне аңлый. Ничек тә күңелемне күрергә тырыша. Авырсам, тизрәк табиб чакыра. Мине карар өчен эшен дә ташлады. Башкача булмый, ялгыз гына тора алмыйм. Елга бер тапкыр үпкәм шартлый. Узган ел да кабатланды. Улым белән ирем телевизор карый, мин кечкә аш әзерли идем. Егылганмын да киткәнмен. Ирем тизрәк Теләче хастаханәсенә алып киткән. Районга Казан табибы килеп, миңа операция ясаган. Аннары безне Казанга алып киттеләр. Шул вакытта ирем мине бер минутка да ташламады. Казаннан кайтып киткәндә, бүлек мөдире палатага кереп озатып калды. Иремнең аркасыннан сөйде. «Син көчле ир-ат икәнсең, хатыныңны сакла», – диде. Аллага шөкер, ирем бер зарланмый.

Мария өйдәге эшләрне эшләргә тырышса да, аңа кеше ярдәме кирәк. Янында йә улы, йә ире икән. Ире эшләмәгәч, маллар асрый башлаганнар. Әмма аларга да акча күп кирәк. Азыгын алу кыйммәткә төшә, диләр. Мариянең пенсиясе генә җитми. Җитмәсә, кислород аппаратын гел алыштырып торырга кирәк. Дарулар да күп эчә.

– Миндә өч төрле аппарат бар. Йоклаганда бер төрлесен куям. Урамга чыкканда көчлерәге кирәк. Утырып торганда өченчесен куябыз. Элек мин, кешеләрдән оялып, өйдә генә утырдым. Дүрт стена туйдырды. Бик арыдым. Хәзер инде яшәп калырга тырышам. Ирем кая гына йөртми. Аппаратны кешегә күрсәтмичә, яшереп кенә куеп, клубка да чыгабыз, урманга да барабыз, кунакка да йөрибез, – ди Мария. – Яратуны кочаклашу-үбешү дип уйлаучылар да бар. Әмма мин чын яратуның ни икәнен беләм. Ирем мисалында әйтер идем. Аның миңа булган мөнәсәбәте, кайгыртуы, мине яшәтергә тырышуы ул ярату! Әнисе баласын кадерләгән кебек мине карый. Кайчак иң тәмле ризыгын үзен ашамыйча миңа бирә. Миндәй авыру белән яшәү җиңел түгел. Түземлек, сабырлык та кирәк.

Мария минем белән дә көчкә генә сөйләште. Тыны кысыла. Җитмәсә, күңеле тулып елап та ала. Хәленең кыен икәнен ишерми. Аны яшәтер өчен, кислород аппараты кирәк. Үзенекеләр инде искергән. Шуңа да мәрхәмәтле кешеләрнең ярдәменә өметләнә.

Мария Шароновага ярдәм итәргә теләүчеләр өчен: 89872895670 телефон номеры Саклык банкы картасына бәйләнгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

САНИЯ ӘХМӘТҖАНОВА:
«ТЕЛЕБЕЗ – ХАСТА ТУКАЙ ХӘЛЕНДӘ»

Шагыйрь белән әңгәмә, телисеңме син, теләмисеңме, ахыр чиктә барыбер җанга тигән күренешләр, вакыйгаларга барып тоташа. Сания апа ӘХМӘТҖАНОВА белән дә юбилей мөнәсәбәте илә күтәренке рухта бер матур, фәлсәфи әңгәмә корырбыз дип ниятләгән идек юкса. Шагыйрь туган телебез, иҗат әһеленең бүгенге хәл-яшәешенә күз йомса, шагыйрь була алмый торгандыр ул.

– Сания апа, шигърият ул – ...
– ...ирек. Җан, фикер, сүз хөрлеге, уйларның ирекле очышы. Бәйсез җанда гына чын шигырь туа ала. Үзеңә чикләү саласың икән, димәк, алдашасың. Бу инде шигърият түгел. Бу – уйдырма. Чынбарлыктагы киртәләр аша сикереп, читлекләрне ватып, араннарны җимереп, җан шигырьдә бәйсезлеккә ирешә. Шөкер, рухны сафларга, иң әүвәл – догалар, аннан инде, түгелеп сафланырга шигырьләр бар. Тик синең җан авазыңны, бәгырь аһыңны сеңдергән көйле юлларның һәркайсы да ирекле очыштамы, әллә кайберләренең канат очы киселгәнме? Менә монысы инде – башка мәсьәлә.

:: Иҗатны хатын-кызныкына, ир-атныкына бүлү дөресме?
– Гомумән алганда, уртак бер исем белән аталса да, хатын-кыз шигърияте дә, ир-ат шигърияте дә үз асыл сыйфатларына ия, билгеле. Хатын-кызның эчке дөньясы, тоемлавы, ана буларак хисләре, дөньяга карашы ир-атныкыннан үзгә бит. Болар барысы да шигърияттә чагылыш таба, билгеле. Риза Фәхретдин үз заманында мондыйрак эчтәлектәге сүзләр әйтеп калдырган: хатын-кызлар, ана кеше буларак, балаларга якынрак торганга күрә, алардан ир-атларга караганда яхшырак мөгаллимнәр чыгачак. Менә мин дә, хатын-кызлар, ана кеше буларак, балаларны яхшырак белгәнгә, аларны төрле хәл-вакыйгалар вакытында күзәтеп торганга, сөйләшү-аралашуларын ишеткәнгә, алардан яхшырак балалар язучысы чыгадыр, дип уйлыйм. Укытучы хатын-кыз әдип-шагыйрьләребез – моның матур мисалы. Хатын-кызны гомумән шагыйрьгә санамаучы ир-ат каләмдәшләребез дә бар.

> Миңа калса, кайбер ир-ат язучылар мәхәббәт кишәрлекләрендә ялкау кыймылдап, 3–4 строфалык чи «покос»лар калдырып, бер урында таптанып торганда, ир йөрәкле хатын-кыз шагыйрьләребез, әдәби мәйданда аяк терәп, нык селтәнеп, покосларын киң алдырып, үз юлыннан чыкмый алга баруын белә.

:: Шагыйрь елъязмачы ролен үтәргә тиешме? Хәер, ил-көн вакыйгаларына үз фикереңне шигъри телдә әйтү соңгы арада популярлашты да кебек.
– Синең әсәрләрең хәзерге көн укучысы өчен генә язылмый бит. Аларны күпмедер вакыттан соң укыгач та, шул чор, вакыйгалар, тормыш-көнкүреш, кешеләрнең тышкы кыяфәте күзалланырга тиеш. Дөрес, бу һәр шигырьдә алай була алмый. Мин татар шагыйре икәнмен, әсәрләремә, һичшиксез, милли хас булырга тиеш. Тик ул ясалмалыктан ерак торсын. Иманлы, тәүфыйклы, чиста, саф, үз халкым кебек горур булырга тиеш минем иҗатым да. Син һәр вакыйганы тизрәк шигырьгә кертеп куясың, диләр кайчак. Булсын! Бу вакыйга иртәгә инде тарих кына булып калачак. Мин бит милләтемне зурлый яки бик үк зурламый, үрнәк булырлык яки сабак бирерлек хәлләр турында язам.

Тиздән Татарстан китап нәшриятында чыгачак яңа китабымда андый күңелле дә, фаҗигале дә күренешләрне чагылдырган шигырьләр шактый икән. Алар нибары соңгы ике елда иҗат ителгән. Ул шигырьләр берсе дә, тукта, елъязмачы булыйм әле, дип язылмаган инде. Вакыт тиз уза. Укып карыйм да, менә бу вакыйга бу вакытта булган икән, дип, шигырьдән карап искә төшерәм. Вакыйгалар еш алышына, алар артыннан өлгереп тә булмый. Күңеллерәк, матуррак, төслерәк шигырьләр иҗат итәсе килә.

:: Сез талантлы спортчы Камилә Вәлиеваны яклап та шигырь яздыгыз. Бу фикерне күпме кеше ишетте?
– Камилә Вәлиева турында мин берничә шигырь яздым. Аның исеме белән хештег куелгангадыр, социаль челтәрдәге сәхифәмә дөньяның төрле почмакларыннан йөзмеңнәрчә төрле милләт кешесе кереп, «йөрәк» билгесенә басып, талантлы спортчыбызга теләктәшлек белдерде. Башка вакытта, башка очракта булса, Камиләгә багышланган контентым шулкадәр популяр булыр идеме, әйтә алмыйм. Монда безне – төрле милләт, төрле кыйтга кешеләрен телгә, дингә карамыйча, Камиләбезнең талантына соклану һәм аңа ярдәм итү теләге берләштерде дип уйлыйм. Бер-ике каршы фикер дә булмады түгел. Ни кызганыч, алары үзебезнекеләр, үз татарларыбызныкы иде.

:: Бушап калган нигез, ялгыз картлык, заман, милли мәсьәләләр – сезнең шигърият зур проблемаларны күтәрә. Юкса кайбер ир-ат шагыйрьләр дә мәхәббәт шагыйре булудан ары узмый...
– Кемне нәрсә борчый, җанын нәрсә талкый – шул хакта сырлыйдыр инде. Авырткан җиргә гел сыйпап-сыпырып торган кебек. Мин ул темаларга язасым килгәнгә түгел, язмый кала алмаганга язамдыр, мөгаен. Мәхәббәт темасы дигәннән, мәхәббәт ул күптөрле бит. Минеке дә туган телгә, әти-әни нигезенә, авылдашларга, эчкән суым, тәпи атлап киткән җиремә мәхәббәт. Әле яңарак кына туган ягым Арчада кунак булып, иҗат кичәмне бәйрәм итеп, кабат иҗатка рухланып килдем. Мин якташларымның үземә карата иң саф, иң самими ярату, хөрмәт хисләрен тойдым. Аларны зурлап, кадерләп, яратып язган шигырьләремнең кайтавазы иде бу, минемчә.

:: Сезнең өчен тыелган тема бармы?
– Коръәндә, динебездә тыелган әйберләр минем өчен дә тыелган. Әдәби әсәрләр кешедә рухи сафлык, тормыш сөючәнлек, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләргә тиеш. Шуңа күрә алар әдәби-нәфис басма дип аталадыр да. Мин кечкенәдән бозыклык, пычраклык, кансызлык турында укырга, андый фильмнар карарга яратмадым. Безнең телебез бай. Иң усал фикерне белдерү өчен дә иң матур, үтемле сүзне эзләп табарга була. Сүзлекләр белән генә дус булырга кирәк.

:: Ә колачлап эшлисе килгән тема нинди?
– Иҗади планнарым, кызыккан темаларым бар. Язуга караганда, минем өчен әзерлек этабы катлаулырак. Аерым шәхесләргә багышланган әсәрләр иҗат итәргә теләсәң, аеруча күп укымыйча, эзләнмичә, әзерләнмичә генә булмый. Без бер төрле уйлыйбыз, Күктә башкача хәл итеп куелган булу бар. Кулдан каләм төшкәнче язарга насыйп булсын инде.

:: Хатын-кыз шагыйрьгә танылу, әйтик, Тукай премиясен алу җиңелме?
– Мин быелга кадәр Тукай премиясе тапшыруны бәйрәм тантанасы буларак кына кабул итеп килдем. Ләкин моңа кадәр дә, читтән карап кына, Тукай премиясе өчен көрәшүчеләрнең хәлләрен күреп-аңлап, аларны кайчакта кызганып та, теләктәшлек белдереп тә йөргән булды. Әмма бу вакыйганың быелгы кебек үк күңелгә үтеп кергәне юк иде. Сүзем Флера апа Гыйззәтуллина кандидатурасы турында барганны аңладыгыз инде. Олпат язучыбызның иҗаты белән мин яшьтән үк кызыксынып килдем. Остазым Марсель ага Галиев тә: «Күрдеңме әле, «Казан утлары»нда Флера апаңның яңа поэмасы чыккан. Укы, өйрән әнә, шулай итеп иҗат итәләр аны», – дип киңәш бирә иде. Мин, акрынлап, Флера апаның сүз тылсымына бирелеп кереп киттем, әсир төштем. Чыннан да, бүген арабызда язу осталыгында Флера апа кадәр камиллеккә ирешкән, каләменең йөгереклеге, саллылыгы, җитезлеге, кыюлыгы буенча аңа җитәрдәй каләм иясе сирәктер. Ул: «Көннәр буе язам, укыйм һәм тагын язам», – ди. Соңгы вакытта бигрәк тә якынаеп киткән идек. Кайсыдыр бер газетада шигырьләрем чыкса, ул үзенең бәясен бирә. Тукай премиясенә кандидат булуын белгәч тә, фикерләшеп, аралашып тордык. Ул төшеп калыр дигән уй минем башыма да кермәде. Ул үзе дә премия аласына инанган иде шикелле. Бер сөйләшүдә шулай да: «Хәзер бу премияне миңа кирәге юк инде. Мин үземне бөтен тирә-юне дә, эче-тышы да янып көлгә калган, дүрт стенасы гына кагаеп, кара кисәү булып каткан, ялгыз, ташландык өй кебек хис итәм», – дигән иде. Мин, аның премияне алмаганын белгәч, шалтыратырга да курыктым. Ул үзе шалтыратты. «Сания, син миңа чын дөресен әйт: үттемме мин, юкмы?» – дип сорады. Мин нәрсә әйтергә белмичә, үземне гаепле санап, башымны аска иеп, беркавым дәшми тордым. Миңа шушы ил карчыгы, әдәбиятның ак әбие каршында, бөтен татар халкы өчен, бүгенге буын вәкилләре өчен оят булды.

> Безгә бер мыскал иҗатыбыз белән «мин – шагыйрь» дип күкрәк кагып йөрү дә оят бит инде алайса! Бүгеннән каләмне ташларга, шагыйрь исемен күтәреп йөрмәскә, бөтенләй язмаска кирәк болай булгач. Дөрес, каләм әһеле Тукай бүләген алу өчен генә язарга тиеш түгел түгелен. Әмма беркөн иҗатыңны бизмәннәргә салганда, исемеңне башка берәүнең исеменә каршы куйсалар, кем вөҗданы нинди мөһер сугар да кайсының ваемсыз каләм селтәнүе белән исемлектән сызылып атылырсың? Шундый уйлар...

Флера апа инде моңарчы да Тукай премиясенә тәкъдим ителгән булган, нигә ул чакта яклап чыкмадыгыз, дип әйтүчеләр дә бар. Ә бит кичә белән бүгеннең аермасы бар! Бүген безнең телебез, әдәбиятыбыз аеруча яклау көтә. Туган телебез – хаста Тукай хәлендә: үзе бибәһа кыйммәткә ия, үзенең кадере юк.

Быел язучыларга ике Тукай премиясе бирелгән очракта, бу туган телебезне, татар язучыларын яклап белдерелгән матур адым буласы иде, минемчә.

:: Иҗат гаиләгә вакыт калдырмый, диләр...
– Иҗат аргамагы янында кешнәп, иңнәремә мен дип торганда, язып калырга, сылтау тапмаска кирәк. Һәр нәрсәнең үз вакыты була. Тукта әле, менә балалар үсәр дә, шул вакытта язармын дип, каләмеңне читкә тибәрергә ярамый. Яшь вакытта азрак йокласаң да була. Төнлә язарга яки иртән барысыннан да иртәрәк торып булса да, вакыт табарга кирәк.

:: Иң зур теләгегез нинди?
– Һәр вакытта да борчу-мәшәкатьләр дә, авырлыклар да булып торган. Иң мөһиме туасы таңнарга, килер көннәргә ышанычны җуймыйк, өметтә калыйк, кеше булыйк.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

СӨЕП, СӨЕЛЕП ЯШИСЕМ КИЛӘ!

(ХИКӘЯ)

< Ахыры. Башы 15, 22, 29 апрель саннарында

***

«Кайда йөрисең шул гомер, балакаем, сәгатькә карале!» – дип каршы алды әнисе ишек тупсасыннан ук Маһинурны.

– Клуб ихатасында волейбол уйнадык.

– Язмаганны, шушы гомергә тиклем! Клуб баганасының утын төртеп төшерәсе генә бар! Утка җыелган чебен кебек, тоталар да шунда җыелалар. Ни кызыгы бардыр инде шул валибул дигәненең? Кит, битләрең мунчадан чыккан кебек кызарган. Тирли-тирли уйнап, салкын тидер тагын! Алыштыр тизрәк өстеңне.

– Ярый, әни!

Әнисеннән шулай тиз генә котылуына сөенгән Маһинур, ашап та тормый тизрәк юрган астына чумды. Күзгә йокының бер генә мыскал тамчысы килсә, ичмасам! Фәниснең әйткән назлы сүзләре һаман колак төбендә яңгырап тора. «Беркемгә дә бирмим, үземнеке генә буласың!» – ди бит әле! Маһинур шуларны уйлаганга да бөтен тәне буйлап «бала йоннары» йөгерә, тәнен калтыравык ала. Моңа кадәр татылмаган хисләр дулкыны аны бер диңгез эченә алып кереп китә, бер ярга чыгарып ташлый. «Нинди рәхәт икән ул мәхәббәт дигәннәре. И-и, әниләр ничек яшиләр икән ансыз, бер тапкыр үбешкәннәрен дә күргән юк! Олыларга яратусыз яшәү бер дә кызык түгелдер ул?»

***

– Уйлап, уйлап торам да, тагын бер уйлап куям әле, Сабир! Соңгы вакытларда күрше кызы Маһинур, кайчан карама, гел кечә як тәрәзәләре аша безне күзәтә. Әллә ничә искә алдым шуны. Жалоба язганнар, диләр бит, Фазылгаян эше түгел микән?

– Булмас! Фазылгаян андый эшкә бармас! Халык контролен җитәкләргә юкка куелмаган инде, ни дисәң дә, үзең намуслы булмасаң, башкаларны ничек тикшерәсең.

– Аптырап әйтүем инде. Һаман да күз алдыннан кызлары китми шул. Алай дисәң, хатыны белән безнең Зарифа – ахирәтләр. Шулай шул, син әйтмешли, булмас. Күрәләтә ялганга да бармаслар, ахирәтенең туганнарына начарлык та эшләмәсләр. Зарифа апаны әйтәм әле, күршеләргә килә, безгә керми. Әллә ничә чакырдым, килгәнен күреп. «Вакытым юк!» – дигән була, үзе – кайчан карама, Хәдичәләрдә. Соңгы вакытларда бигрәк тә еш күренә башлады. Авылның икенче башыннан иренми ничек йөри ул? Туган итмәде инде безне элек-электән, абыең да юаш булды, бер сүз әйтә белмәде. Әнкәй безнең белән яшәмәсә, аяк та басмаслар иде, аның хәлен белергә дигән сәбәп белән генә кереп чыккалыйлар. Үзләренә барсаң, ачык чырайлары булса, такта чәйләре юк, такта чәйләре булса – ачык чырайлары.

– Әйтеп, кешене үзгәртеп буламыни? Бигрәк тә Айгыр кушаматлы нәселдән чыккан Зарифа җиңгине.

– Шулайдыр инде. Алтыдагы – алтмышка, диләр бит.

Сабир белән Таһирә бакча өендә тагын хәтсез генә сөйләшеп утырдылар. Бер көн иртән торуларына келәт алдына кемнәрнеңдер ун капчык бодай калдырып чыгып киткәннәрен кабат искә төшереп, баш чайкап алдылар. Ярый әле, башлары эшләп, тиз генә силсәвиткә хәбәр иттеләр. Акт төзеп, кире колхоз амбарына илтеп куйдылар. Кызулык белән, Таһирә капчыкларның берсенә килеп тә тотынган иде, эче бер җирдән кисәк кенә тартылып куйгач, ничек капчыкны кулыннан ычкындырганын да сизми калды. Шул көннән бирле эче авыртыбрак тора инде, бер-бер хәл булмасын дип, коты очып тора. Ни дисәң дә, җиденче ае бит.

Таһирә балавыз да сыгып алды. Кеше алдында гарьлеге ни тора бит! «Карак» дигән даның бер чыкса, гомергә дә аны юып бетерә алмассың. Авыл җирендә бигрәк тә. Эшнең ничек бетәсе билгеле булмаса да, кемнәндер авызыннан: «Башын төрмәдә черетерлек», – дигән сүзләр дә чыккан, имеш. Халыкның күпчелеге элеккечә, берни булмагандай әллә каян исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашып торса да, тынычланырлык сәбәп юк шул әлегә.

– Авырлы булмасам, җиңелрәк үткәрер идем әле, бәлки.

– Ярый, көяләнмә, Таһирә, бар да яхшы булыр! Керик, иртәгә бәйрәм түгел. Сиңа да ял кирәк, көне буе аяк өстесең. Яшьләреңне сөрт, балалар сизмәсен!

***

Мәктәптән кайтканда, колхоз идарәсе янында торган таныш машинаны күргәч, Маһинур якындагы тыкрыкка борылып кереп китте. «Дәү әниләр чакырган иде», – диде бергә кайтып барган сыйныфташларына. Фәнисне бик күрәсе килсә дә, башкаларга танышлыкны белдерәсе килмәгәнгә шулай эшләде. Әниләренә, укытучыларга барып ишетелсә, аннан «Беттең!» дигән сүз. Өстәвенә Таһирә апаның эше аларның мөнәсәбәтләренә килеп тоташты. «Әниләрне әйтер идем инде, шул Зарифа апаның сүзенә карап, үзләрен дә, мине дә нинди хәлгә куйдылар. Җитмәсә, миннән, ялганлап, фәлән көннәрне, фәлән сәгатьләрне Сабир абый трактор белән капчык-капчык әйбер төяп кайтты, дип яздырттылар. Ул язуны, әйткәндәй, кая куйдылар икән алар? Ертып ыргытырга кирәк!» Маһинур шул уйлары белән дәү әниләренә килеп керде. Чәй эчәргә генә утырганнар иде, капка төбенә чыжылдап милиция машинасы килеп туктады. «Ну бу Фәнис, бөтенләй башсыз әллә, көпә-көндез минем янга килгән», – дип, комачтай кызарып, ишегалдына чыкты. Капкадан әнисе килеп кергәч, йөрәге «жу!» итеп китте.

– Кызым, сине тикшерүче чакырткан. Дәрестән соң өйгә кайтмагач, дәү әниеңдәдер дип, монда алып килдем инде шоферын.

– Тикшерүче?

– Әйе, күрше Таһирә апаңнарның эше белән. Синең ничек урлашканнарын күреп язган язуыңны да жалу янына куйган идек. Әллә ни сорамаслар, шул язганнарыңны гына кабатлап сорарлар диде әтиең. Берүк уйлап сөйлә, артыгын ычкындырма, яме, кызым!

Капкадан чыкканда, Маһинур, җәй буе күпереп үсеп, көзен тагын да ныгып киткән үләннәргә абынып, егылып китә язды. Башын күтәрергә дә оялып, машинага кереп утырды. Тик... рульдә икенче кеше булып чыкты. Ул чак кына: «Фәнис кайда?» – дип сорамады. Дөрес, аның булмаганына ул сөенде генә. Нинди оят! Нигә генә, әниләре сүзенә карап, ялган эшкә барды икән? Кем уйлаган бит, кем уйлаган, дөньяның шулкадәр дә куласа икәнен. «Әгәр дә Фәнис әниләрнең ялган жалобасы турында белсә, миңа әйләнеп тә карамаячак!» – дип, Маһинур юл буена эченнән янып барды.

Унбиш яше тулган Маһинурдан сорауны тикшерүче үзеннән генә алды. Бер агарып, бер күгәреп, тикшерүченең сорауларына җавап биреп чыкканда, әнисе ишек төбендә көтеп утыра иде. Маһинурның агарып киткән йөзенә карап: «Әйдә чак кына хәл ал, аннан кайтырбыз», – дип, урындыкка күрсәтте. Биш минутлап дәшми-тынмый гына утырганнан соң, Маһинур кузгалды. Шул вакытта, ярымачык ишектән тикшерүченең телефон аша кем беләндер сөйләшкәне ишетелде. «Фәнисне моргтан иртәгә алып кайталармы?» Ул көнне Маһинурның идарә коридорында ишеткән соңгы сүзләре шулар булды...

***

Хәдичә белән Фазылгаянда Таһирә кайгысы калмады. Ник шунда тагын җиде йорт тергезеп куймасыннар! Бердәнбер кызларының, тикшерүче яныннан чыккач, кинәт кенә егылып, комага китүе аларны гомердә булмаганны тетрәндерде. «Зарифа сүзенә карап, нинди адымга бардык, нимидлынно барып, бөтенесен сөйләп бирәбез!» – дип елый-елый такмакласалар да, бер атнадан Маһинур күзләрен ачкач, биргән сүзләрен оныттылар. Әлбәттә, моның үзенә күрә сәбәпләре дә бар иде. Беренчедән, аларны Зарифа килеп өркетеп китте: «Жалуны язганда уйларга иде. Нахак яздык дип барып әйтсәгез, утырып куйганыгызны да сизми калырсыз. Хәзер законнар каты, апаем. Үзегезне уйламасагыз, балагызны уйлагыз, әле балнистан кайчан чыгасы билгеле түгел». Зарифаның бу эшләргә бер катнашы юк кеше кебек итеп сөйләшүеннән Хәдичә белән Фазылгаян телсез калдылар. Аларның башына, ниһаять, алар кулы белән Зарифаның үзе теләгәнен эшләгәне барып җитте. «Эше төшсә – үз кеше, эше бетсә – ят кеше» дигәннәре шул була икән», – дип әйтүдән башкасы калмаган ир белән хатын, арт якларына килеп утырганнарын сизми дә калдылар. Ә Зарифа үзләренә кайтып җиткәнче, «чебен тимәс чер иткән» кызны әрләп кайтты.

Маһинурның, чынлап та, кайчан чыгасы билгеле түгел иде. Һушына килсә дә, беркем белән сөйләшмичә, бер ноктага карап ята бирде. Шулай да көненә берничә тапкыр Фәнис исемен кабатлады, аны чакырды. Шушы көннәрдә бөтен районны шаулаткан, кыз баланы хулиганнардан яклаганда кыйнап үтерелгән, милициядә эшли генә башлаган егет белән Маһинурның теленнән төшмәгән Фәнис икесе бер кеше булып чыкты.

Табиблар Маһинурның психикасында тайпылышлар барлыкка килгәнен әтиәнисенә җайлап кына аңлаттылар. Хәдичә белән Фазылгаян ышанырга теләмәсәләр дә, бу чын хакыйкать иде. Олыракларның: «Аллаһ биргән газап дип кабул итмәгез, бу бары тик сынау булырга мөмкин, әмма җәза түгел», – дигәнен кабул итеп, гомерләренең азагына кадәр шуның белән риза булып яшәргә туры килде...

***

– Ахирәт, Маһинур турында тагын төрле имеш-мимешләр йөри, авыр булса да, әйтим инде.

Зарифаның нәрсәгә ишарә иткәнен Хәдичә аңласа да: «Сөяксез тел ни димәс», – дип, ипи камырын басуын дәвам итте. Ипи кисмәгенең төбе кубарылып килеп төшсә дә, аптырарлык түгел иде бу мизгелдә – җан ачысы белән бергә кушылган физик көч әллә нәрсәләр майтарырга сәләтле.

Баш мие эшчәнлегенә бәйле артык җитди тайпылышлар булмаганга, Маһинурга җиңел эшләр рөхсәт ителгән иде. Башта мәктәпкә җыештыручы булып урнашты. Егерме бер яше тулгач, колхозда атлар караучы, армия хезмәтенә сәламәтлеге аркасында бармый калган Хәкимҗанга димләп, никах укыттылар. Тик кияү тиешле кеше артык кызу холыклы булып чыкты. Юк-бардан сәбәп табып, кулын да уйната башлагач, аерып алып кайттылар. «Башым авырта», – дип, бераздан эштән дә туктады Маһинур. Җәй көне, күрше-тирә кызларына ияреп, амбарга йөри башлады. Ике атналап эшләгәч: «Әни, төнге сменага күчәсе килә, көндез эссе», – дия башлады. Күршесе Таһирә әйтте дә бит: «Көндез үзем күз-колак идем, төнлә искә алучы да булмас, Маһинур авыррак булыр, ничек тә кирегә күндерегез», – дип. Их, шунда тыңлыйсы калган да бит! Колхозга урып-җыюга булышырга килгән шоферларның әле берсенә, әле икенчесенә утырып йөри башлаганын да иң соңгылары булып ишеттеләр шул. Бикләп дигәндәй, кыш буе өйдә утыртсалар да, яз җиткәч, Маһинурның тагын эшкә чыгасы килә башлады. Бер авыз пешкәч, өреп кабыйк дип, идарәгә җыештыручы итеп урнаштырдылар. Өч айлап эшләгәч, иллегә җитеп килгән, каравыл торган биш бала атасы белән мөнәсәбәтләре тирәнгә керә башлаганны ишеттерделәр. «Үзе кочакка кергән хатын-кызны куалап җибәрергә мин юләр түгел, юләр кызыгызның күңелен күргәнгә рәхмәт әйтергә кирәк!» – дип шаркылдап көлеп торган Мәҗитне өзгәләп ташламаудан көчкә тыелып, Фазылгаян шәп-шәп итеп өйләренә атлады. Шул төнне аның гәүдәсен абзарда асылынган килеш таптылар...

– Мин әйтәм, Мәхмүтҗан малаеннан юкка аерып алып кайттыгыз, кул күтәрә дип, икесе дә бер рәвеш...

Зарифа җөмләсен тәмамлый алмады, Хәдичә камырлы кулы белән аның чәченнән эләктереп алды да ишектән өстерәп алып чыгып китте.

«Нишлисең, ахирәт, җибәр!» – дип, Зарифаның такмаклавын, ишетсә дә, ишегалдында казынып йөргән тавыклар гына ишеткәндер. Хәер, аларда да кеше кайгысы юк иде бугай, беренче тапкыр явып эрегән кар астыннан азык эзләве ләззәтләрәк тә, кызыклырак та иде.

Шушы көннән Зарифа өчен бу йортның ишекләре мәңгелеккә ябылды.

***

Бу хәлләрдән соң бик күп еллар үтте, сулар акты. Авылда шушы тарихны белгән, аңа кагылышлы кешеләрнең дә күбесе инде күптән гүр иясе булган. Ә менә Таһирә белән Сабирның тумаган сабые, бәлки, исән дә булыр иде әле. Аңа кадәр дә, аңардан соң туган балалары да, шөкер, таза-саулар. Сабир абзый гына үткән кыш гүр иясе булды. Төпчекләре тәрбиясендә яшәгән Таһирәттәй тормышларында кичергән бу күңелсез сынауны, бәлки, әле дә онытмагандыр. Зарифаның да вафатына биш елдан артык вакыт узып китте. Соңгы елларда ул дин юлына басты, биш вакыт намазын калдырмады. Бәлки, теге дөньяда гөнаһлары өчен җәза алу өркеткәндер.

Маһинур каршысында яткан, таушалып-майланып беткән дәфтәрне ача да сызгаларга тотына. Үзе өзек-өзек нидер сөйләнә: «Әнә, әнә капчыклар бушаталар!.. Фәнис, мин сине яратам!.. Тикшерүче абый, мин дөресен сөйләмим!.. Әни, ачуланма, минем дә башкалар татыганны татыйсым килә, сөеп, сөелеп яшисем килә...»

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»нан ай саен бер бүләк

1 **ЯЗЫЛ!**
2022 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**
30 майга кадәр газетага язылучылар арасында
ТАНДЫР һәм **ӘФГАН КАЗАНЫ** уйнатабыз

П2435
җомга саны
488 сум 10 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1099 сум 32 тиен

Май ае өчен квитанцияләр 2022 елның 8 июнена кадәр кабул ителә. Бүләк 9 июнь көнне уйнатылачак.

Акция 2022 елның 29 апреленнән башлап 17 июленә хәтле дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru
16+

Реклама

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕЛӘРЕ

Тандырда пешкән ризык тәмле һәм затлы!
Иң күп сайлау мөмкинлеге – «Тандыр 24» кибетендә.
Сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирерләр.

«Тандыр 24», ТР, Казан шәһәре, Зәкиев урамы, 4 нче й., сул канат, 2 нче кат

тел.: +7-917-919-80-01

Реклама

Корыч казаннар, әфган казаннары, мангал, казаннар өчен мичләр. Безнең кибеттә табигатьтә ризык әзерләү өчен бөтен төр товарлар да бар.

тел.: +7-905-020-00-39

«Мир казанов 116», ТР, Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 100 нче й., элмә тактасы – «ЭКОМАРКЕТ»

Реклама



Рәис Габдулла

29 апрель санында чыккан сканвордның җаваплары

Горизонталь буенча: сыман, Оле, Бенин, Ивеко, чәер, Натс, Мом, агава, Орли, рун, ил, Ажур, Отто, өмет, фабула, жирәбә, Фан, Ниш, Окс, кысыр.

Вертикаль буенча: чуар, фок, Гуам, Жак, Еманжелинск, Сабиров, ут, мавр, Фәнис, Минин, таби, Иваново, Бәшәр, нонет, туу, Ксилит, Рено, Илона.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Татарлар турында беренче нәфис фильмның исеме нинди була?
А) «Сәйәр»;
Б) «Булат Батыр»;
В) «Күктау».

2 Көнбатыш Рим империясенең таркалуы.
А) 476 ел;
Б) 632 ел;
В) 962 ел.

3 Угра буендагы каршы тору ничәнче елда була?
А) 1395 ел;
Б) 1480 ел;
В) 1500 ел.

4 1966 елдан Камал театрының баш режиссеры.
А) Марсель Сәлимҗанов;
Б) Хәлил Әбҗәлилов;
В) Илья Репин.

5 «Рәнҗеткәннәр сине, рәнҗеткәннәр,
Бик тә рәхимсез шул бу дөнья.
Көлә-көлә йөгереп барган чакта
Үсеп чыга юлга зур кыя».
Бу шигырь юлларының авторы?
А) Саҗидә Сөләйманова;
Б) Фәнис Яруллин;
В) Илдар Юзеев.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) Б; 4) А; 5) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 263

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+